• ВАКЫЙГА •

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ!

2018 елның 2 яртысына язылу бәясе - 132 сум.
Язылу индексы: П4333

• ВӘГАЗЬ •

ЗӨЛХИҖҖӘ АЕ ЯКЫНЛАША

12 августтан хаҗ ае башлана. Бу айның фазыйләтләрен искә төшерик.

6 бит

• КОРБАН •

КОРБАН ЧАЛУ АЛЛАҺКА ЯКЫНАЙТА

Корбан чалу кемгә вәҗиб? Корбан чалу тәртибе, итне тарату тәртипләре.

10 бит

• ТӘРБИЯ •

АТА-АНАЛАРГА ФАЙДАЛЫ МӘГЪЛҮМАТ

Мөселман балалар бакчалары, хәләл туклану каралган мәктәпләр исемлеге.

13 бит

№ 7 (276) *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *шәүвәл – зөлкагъдә 1439*

Июль, 2018

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

Унберенче тапкыр Республикакүләм мөселман балалар Сабан туе узды

Башкортстан Диния нәзарәте вәкилләре Татарстан мөфтиятендә булды

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Башкортстан мөфтиенең беренче урынбасары Айнур хәзрәт Арсланов җитәкчелегендәге делегация булды. Башкортстан мөфтияте вәкилләрен Камил хәзрәт Сәмигуллин кабул итте. Кунакларны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлеге кызыксындырды. Очрашу барышында Татарстан мөселманнары лидеры «Хозур» нәшрияты эшчәнлеге белән таныштырды, үткәрелә торган чаралар һәм башланып киткән проектлар турында сөйләде. Ике як дини оешмалар арасында хезмәттәшлек алып бару һәм үзара мөнәсәбәтләрне ныгыту мәсьәләләрен карады.



Мөфтият вәкилләре тикшерү изоляторына һәм төзәтү колониясенә барды

Татарстан Республикасы мөфтие киңәшчесе, иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзасы Илдар хәзрәт Баязитов, шулай ук «Ярдәм» ислам хәйрия фонды президенты, иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзасы Илһам Исмәгыйлев һәм дәгъват бүлегенең әйдәп баручы белгече Марсель Мингалиев Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсенә караган 1 нче тикшерү изоляторында булды. Учреждениедә кырыктан артык кеше экстремистлык маддәсе буенча җәза үтә. Визит барышында хәзрәтләр яшәү корпусларын карадылар, мәҗбүри тоту урыннарын тикшерделәр, тоткыннар белән әңгәмә үткәрделәр. Рейд нәтиҗәләре буенча мөселман руханилары вәкилләре тоткыннардан шикаятләр булмавын һәм биналарның торышы санитария-гигиена нормаларына туры килеп канәгатьләнерлек булуын билгеләделәр. Учреждение администрациясе тарафыннан матди-көнкүреш базаны яхшырту буенча билгеле бер чаралар күрелә, нигездә, 1 нче тикшерү камерасында планлы ремонт ясалган.

Моннан тыш, Илдар хәзрәт 18 нче төзәтү колониясендә булды, ул шулай ук биредә тоткыннар белән аралашты, аларны тоту шартлары белән танышты, китапханәдә экстремистик әдәбиятның булу-булмавын һәм рөхсәт ителгән дини китапларның җитү-җитмәвен карады. Тоткыннар белән алда торган Корбан бәйрәме турында әңгәмә үткәрделәр.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе белән берлектә 2016 елдан республикабыз төрмәләрендә җәза үтүче мөселманнар белән колонияләрдә экстремизм күренешләрен кисәтү максатыннан зур эш алып бара. Нәзарәт эшчәнлегенең бу юнәлешен алып бару өчен республикабызның 11 төрмәсендә имам беркетелгән. Хезмәттәшлек нәтиҗәсе буларак, Татарстанның җәзаларны үтәтү учреждениеләрендә гыйбадәт бүлмәләре булдырылды, анда 500 артык тоткын намазларга йөри, Коръән укый һәм башка дини йолаларны башкара.

Казанда ТР МДН Голамәләр Шурасының чираттагы утырышы узды

Җыелыш Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә үтте, аның эшендә Шураның гыйльми сәркатибе Рөстәм хәзрәт Нургалиев, Казан казые Габдулла хәзрәт Әдһәмов, РИИ һәм КИУ мөгаллимнәре Равил хәзрәт Бикбаев һәм Рамил хәзрәт Гыйззәтуллин, Казанның берничә мәчет имам-хатыйбы катнашты. Хәзрәтләр «Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә»не яңарту эше барышы турында хәбәр иттеләр. Документ Нәзарәтнең Голамәләр шурасы һәм Казыйлар шурасы тарафыннан 2014 елда эшләнде, ләкин Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның боерыгы белән бүгенге көн вәзгыятеннән чыгып яңарту турында карар кылынды. Моннан тыш, утырыш кысаларында голамәләр Татарстанда намаз вакытлары мәсьәләсен дә карадылар. 2014 елда ТР МДННең Пленум утырышында дин әһелләре намаз вакытларын төбәкнең географик үзенчәлекләрен исәпкә алып, астрономик хисаплар буенча билгеләргә дигән карарга килделәр.

Голамәләр шурасы – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең киңәшмә органы, махсус рәвештә фәнни-дини өйрәтмә мәсьәләләрен өйрәнү һәм чишү максатыннан булдырылган. Голәмәләр шурасы бүгенге көндә Татарстан һәм Россия өммәте социаль-икътисади үсешенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыруда актив катнаша.

2017 елда Голәмәләр шурасы эшчәнлеге банк, инвестиция һәм социаль өлкәләрне күздә тотты, шулай ук дини йолалар һәм тәҗрибәләр буенча мәсьәләләрне карады. Голәмәләр тарафыннан төрле эзләнүләр алып барыла һәм рәсми нәтиҗәләр чыгарыла Татарстан һәм Россия күләмендә зур әһәмияткә ия берничә проект тормышка ашырыла. Алар арасында – «АК БАРС» БАНК ААҖ белән уртак ислам кануннары буенча финанс хезмәтләр һәм хәләл продукция җитештерү өчен аерым технологияләр. Моннан тыш, Шураның эш төркеме тарафыннан торак-төзелеш кооперативлары, иминиятләштерү компанияләре эшчәнлекләре анализланды, мөселман календаренең истәлекле бәйрәм көннәре билгеләнде, дини йолалар стандартлаштырылды, имамнар һәм казыйлар өчен никахларны теркәү һәм талак мәсьәләләре буенча кагыйдәләр җыентыгы бастыру әзерләнде. Татарстан голәмәләре эшчән-леге чит илләрдә югары бәяләнүен шулай ук Шура әгъзасы Рөстәм хәзрәт Нурга-лиевның фәтвалар буенча Евразия ислам советының рәис урынбасары булып сайлануы да күрсәтә.

Татарстан мәдрәсәләрендә кабул итү кампаниясе бара

Татарстан Республикасының мөселман уку йортларында кабул итү кампаниясе бара: яңа белем алырга дип 2018 ел абитуриентлары мәдрәсәләргә киләләр. Кичәге мәктәп укучылары гаризаларын көндезге бүлеккә бирсәләр, олырак яшьтәгеләр кичке һәм читтән торып уку мөмкинлеген карыйлар. Гомумән, республиканың мөселман уку йортлары көндезге бүлеккә 300-дән артык шәкерт кабул итәргә әзер, кичке һәм читтән торып уку бүлекләрендә 650 кеше өчен урын каралган.

Татарстанда мәгариф системасы өч баскычтан тора: башлангыч, урта һәм югары. Башлангыч белемне мәчет каршындагы курсларда алып булса, урта белемне мәдрәсәләр, югары белемне Россия ислам институты, Казан ислам университеты (бакалавриат, магистратура) һәм Болгар ислам академиясе (магистратура, докторантура) бирә.

Татарстан мәдрәсәләрендә урта һөнәри мөселман белем стандарты шулай ук башлангыч, төп һәм югары дәрәҗәдәге белем бирә. Стандартка «Гарәп теле», «Дин тарихы», «Психология һәм педагогика», «Хокук нигезләре», «Татар теле һәм әдәбияты», «Татарстан һәм татар халкы тарихы», «Россиядә ислам тарихы», «Ислам дине тәгълиматы», «Коръәнне уку һәм ятлау», «Коръәнне уку кагыйдәләре (тәҗвид)», «Коръән белеме», «Коръән тәфсире», «Гыйбадәт кылу нигезләре», «Ислам хокукы», «Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы», «Хәдис белеме», «Вәгазь уку нигезләре һәм имамның бурычлары», «Ислам агымнары», «Ислам фәннәрен укыту методикасы», «Әхлак», «Ислам тарихы», «Мантыйк» кебек дәресләр керә.

Татарстанның мөселман уку йортларындагы көндезге бүлектә төп белем 3 ел дәвамында укуны күз алдында тота, югары дәрәҗә – 5 ел. Мәдрәсәләрнең күбесе төп укыту программасы буенча белем бирә. Бары тик «Мөхәммәдия» Казан мәдрәсәсе генә югары дәрәҗәдәге белем бирә.

Мәдрәсәләр абитуриентларга дин әһеле һәм мөселман дини оешмалары хезмәткәре белгечлеген алырга тәкъдим итә. Укып чыгучыларга «Имам-хатыйб», «Ислам нигезләре һәм гарәп теле укытучысы», «Гарәп теле укытучысы һәм тәрҗемәчесе» квалификацияләре бирелә. Дини белемнән тыш, шәкертләр өстәмә һөнәри белемгә дә ия булалар (умартачы, автомобиль йөртүче, тегүче h.б.). Кайбер мәдрәсәләр үз шәкертләренә югары уку йортлары белән хезмәттәшлек нигезендә читтән торып параллель рәвештә югары дөньяви белем алу мөмкинлеген дә бирәләр. Мәдрәсәдәге төп программаны үзләштереп, укуны Казан ислам университетында югары дини белем алып дәвам итәргә мөмкин. Биредә көндезге бүлектә уку дәвере 4 ел тәшкил итә, читтән торып уку (бакалавриат) 5 ел дәвам итә. Мәдрәсәдә укып чыкканнар тизәйтелгән укыту курсын үтәргә мөмкин. Россия ислам институты яки Казан ислам университетын тәмамлаучылар магистратурага, шул исәптән Болгар ислам академиясе магистратурасына да керә ала.

Студентларга уку дәверендә тулай торакта урын һәм ашау каралган, кайбер мәдрәсәләрдә спорт төрләре буенча түгәрәкләр эшли.

Мәдрәсәләрдә югары квалификацияле, югары дөньяви һәм дини белемгә ия белгеч-укытучылар укыта.

Көндезге уку бүлекләренә керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документлар тапшырыла:

- үрнәк буенча мәдрәсә директоры исеменә гариза;
- үрнәк буенча анкета;
- паспорт копиясе (1 нче бит һәм прописка);
- 086 формасы буенча медицина белешмәсе;
- 26 формасы (прививкалар) буенча шәхси медицина картасы;
- 3х4 форматлы 4 фоторәсем;
- белем алу турында документ (оригинал);
- мөхтәсибәттән яки Диния нәзарәтеннән юллама.

Документлар 1 августка кадәр эш көннәрендә 9.00-дән 15.00-га кадәр кабул ителә.

Кабул итү имтиханнары түбәндәге предметлар буенча уздырыла:

1) татар теле – инша, изложение;
2) рус теле – тест (яки БДИ нәтиҗәләре буенча);
3) Россия тарихы – тест (яки БДИ нәтиҗәләре буенча);
4) Ислам нигезләре – әңгәмә.

Көндезге бүлеккә укырга 9 яки 11 сыйныфларны тәмамлаган 15 яшьтән алып кызлар һәм егетләр кабул ителә.

Кичке һәм читтән торып уку бүлекләренә урта (тулы) гомуми, урта һөнәри яки югары белемгә ия ир-атлар һәм хатын-кызлар кабул ителә. Уку дәвере 4 ел тәшкил итә. Югарыда күрсәтелгән документлар 1 августка кадәр кабул ителә. Керү имтиханнары августта башлана. Тулырак мәгълүмат http://magarifrt.ru һәм мәдрәсәләрнең сайтларында.

■ **dumrt.ru**

Болгар академиясе чит ил шәкертләрен кабул итә башлый

Киләсе уку елында Болгар ислам академиясе чит илләрдән укырга килүче шәкертләрне кабул итә ала. Бу турыда академиянең ректоры Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин хәбәр итте. Ректор сүзләренчә, беренче уку елында уку-укыту системасы җайга салынды, шул сәбәпле чит ил шәкертләрен чакыруга басым ясалмаган.

Быел Болгар академиясендә Таҗикстан, Үзбәкстан, Кыргызстан һәм БГӘ гражданнары гыйлем алырга теләк белдергән. Бу шәкертләр рәтенә Казахстаннан да кушылучылар булыр, дип фаразлыйлар. Татарстан Президентының Казахстанга рәсми визиты вакытында Нурсолтан Назарбаев академиянең эшчәнлегенә кызыксыну белдергән.

Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин бар шәкертләргә кебек үк, чит ил шәкертләренә дә академиягә керү өчен имтиханнар тапшырырга кирәклеген искәртте. Абитуриентларга куелган төп таләпләр арасында – бакалавр дипломына ия булу һәм иркен рәвештә гарәп телен белү, чөнки академиядә күпчелек фәннәр Коръән телендә укытыла. Болгар академиясендә Сүрия, Гыйрак, Йәмән, Иордания, Фәләстыйн һәм башка илләрдән күренекле руханилар, мөгаллимнәр укыта.

Академиягә кабул итү турында тулы мәгълүмат bia.tatar сайтында китерелә.

«Дини культурабызны үстерәсе иде»

Чаллы мөхтәсибәтенең аксакаллар Шурасын борчыган мәсьәләләрнең берсе – дини культурабызның түбән калуы. Мәчет, дин әдәпләрен гади халык кына түгел, ә намазга йөрүчеләр дә белеп бетерми. Вәгазь барганда мәчет намазы укулар, намаз гыйбадәтен кешеләр йөрергә комачаулый торган урыннарда, хәтта баскычта кылу, намаз залында кесә телефоннарын сүндермәү – болар инде гадәти күренешләр. Күпләр үзләренең сораулары белән мәчеткә нәкъ намаз барган вакытта шалтыраталар. Һәм кабат шалтыратып: «Нигә телефонны алмыйсыз?» – дип ачуланалар. Монысы да гаҗәпләндерә. Югыйсә хәзер намаз вакытлары Интернет челтәрендә дә, газеталарда да, аерым битләрдә дә күп таратыла. Гаҗәпләндерә торган башка күренешләр дә бар. Күптән түгел намаз укып чыкканда безне мәчетебез дежурные янында бала күтәргән яшь кенә хатын каршы алды. Аның артында кечкенә эт күтәргән 10-12 яшьләр тирәсендәге малай да бар иде. Хатын өшкертү мәсьәләсе белән кызыксынды. Мин исә аңа башта мөселман кешесенә фатирында эт тотуның гөнаһлы эш булуын аңлата башладым, балагызның авыруы шуннан булырга да мөмкин, дип искәрттем. Хатын баласының сәламәт булуы, өшкертергә чирләп киткән этләрен алып килүләрен белдерде. Мин мондый эшнең шәригатьтә булмавын аңлаткач: «Мәчеттә өшкерергә ярамаса өйгә бер бабай җибәрсәгез дә ярый», – дип нәтиҗә ясады. Бабайлар нәрсә әйтергә белмичә, аптырап карап тордылар.

Дөрес, мондый хәлләр еш кабатланмый. Мәчетебез ачылган беренче елларны бер татар бабае этен кышкы салкыннарда, үзем астын җыештырып торырмын, дигән сылтау белән, мәчетебезнең бер җылы бүлмәсендә асравыбызны үтенгән иде. Аңа да шәригать таләпләрен яхшылап аңлатырга туры килде. Динебез нигезләрен, мәчет әдәпләрен белмәү шундый күңелсез хәлләргә китерә.

Аксакаллар Шурасының мөһим бурычы – яшьләребезне олыларны хөрмәт итүгә, әдәпкә, әхлаккә өйрәтү. Әле генә үзем белән булган бер вакыйганы искә төшерергә телим. Күрәм: бер егет тәһарәтханәдән ялангач, йөзен сөртмәгән килеш чыкты. Җитмәсә утны да сүндермәде. Мин аңа бит һәм аяк сөлгеләренең булуын, намаз залына сөртенеп чыгу кирәклеген, утны сүндерүнең исрафка юл куймау икәнлеген искәрттем. Ул болай дип җавап бирде: «Мин суның тәнемдә кипкәнен телим. Утны сүндерү кирәкми, чөнки ут ул – нур. Бер Ислам галиме әйткән: «Нурны сүндермәгез, нурны сүндерүче – Исламны сүндерүче», – дигән».

Ул минем мәчеттә кем булып эшләвем белән кызыксынды. Мин имам-хатыйб икәнлегемне әйттем. Ул: «Ут сүндерүгә, су ябуга, сөртенеп чыгуга бәйләнеп, дәрәҗәнне ул кадәр төшермә инде. Хәзер бит демократия. Менә аяк киемен дә мин кайда телим – шунда салып калдырам», – диде.

Яки тагын бер мисал: мәчеткә 18-19 яшьләрдәге кыз белән 30-40 яшьләр тирәсендәге бер ир-ат килделәр. Кызның белдерүенчә, тормышлары җайланып китә алмый икән. «Күптән яшисезме, никахыгыз бармы, ир, хатын хакларын беләсезме?» – дигән сорауга мәчеткә киңәшкә килгән әлеге яшь хатын: «Әле 15 көн генә яшибез, никахны кирәк дип әйтмибез, хәзер никах белән кем яшәсен», – дип җавап бирде. Мондый хәлгә аптырамас җирдән аптырарсың. Югыйсә бу яшь хатын мәчеткә киңәшкә, дип килгән, ә никахның ни икәнлеген дә аңламый, аның ата-анасы да бар, үзе Тукай районының бер авылыннан икән (авыл исемен әйтәсем килми, чөнки анда танышларым да яши).

Дини культурабызны без, әлбәттә, дини гыйлем, аңлату эшләрен җәелдерү, үзебезнең үрнәгебез, хикмәтле эшләребез белән генә үстерә алабыз. Без, дин әһелләре, мәчет аксакаллары, бу эшләрдә активрак булсак идек.

■ **Равил хәзрәт Нуруллин,**
Чаллы мөхтәсибәтенең аксакаллар Шурасы рәисе,
«Туфан» мәчете имам-хатыйбы

«Йөрәк белән күрәбез һәм ишетәбез»

1 июльдә «Ярдәм» милли ислам хәйрия фондының белем бирү-тернәкләндерү үзәгендә бөтенләй күрмәүче һәм начар күрүче кешеләр өчен укыту-дәвалау тернәкләндерү курслары башланып китте. Әлеге курслар РФ Президенты Гранты һәм «Ярдәм» хәйрия фондының үз чыганаклары хисабыннан финанслана. Бер айлык әлеге тернәкләндерү курсларына Самара, Иркутск, Ульяновск, Киров, Оренбург, Омск, Пермь өлкәләреннән, Ставрополь, Краснодар төбәкләреннән, Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия, Дагъстан, Чечня республикаларыннан, Татарстан шәһәр һәм районнарыннан 45 кеше килде.

Июнь башында Казанда күп еллар эшләп килгән «Ярдәм» милли ислам хәйрия фонды Россия Президентының гражданнар җәмгыятен үстерүгә юнәлтелгән Грантын отты. Татарстаннан тәкъдим ителгән һәм җиңү яулаган 58 проект арасында иң күләмле Грантка «Ярдәм» хәйрия фонды ия булды. «Ярдәм» хәйрия фонды өчен күрмәүчеләр һәм начар күрүчеләр белән эшне тагын да нәтиҗәлерәк алып бару өчен мөмкинлекләр артты.

«Йөрәк белән күрәбез һәм ишетәбез» дип аталган һәм бер елга исәпләнгән Грант проекты 2018 елның 11 июненнән эшли башлады. 2019 елның сентябренә кадәр 5 төркем туплау, 225 кешегә белем бирү һәм тернәкләндерү курсларын оештыру күздә тотыла.

Проектның максаты – күрмәүче һәм начар күрүче кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту, психологик һәм медицина ярдәме күрсәтү, җәмгыятьтә җайлашырга, кешеләр белән аралашырга өйрәтү, тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итү. Әлеге социаль проект җәмәгатьчелекнең игътибарын физик мөмкинлекләре чикле булган кешеләрнең проблемаларына җәлеп итү бурычын куя.

Уку-укыту программасына кертелгән һәр предмет, дәреснең, консультациянең үз максаты бар. Дәресләрне үзләштергәннән соң күрмәүче һәм начар күрүче кеше нинди белемнәргә, нинди күнекмәләргә ия булырга тиеш? Тернәкләндерү үзәге укытучылары, үзәккә килеп медицина лекцияләре укучы табиблар, юридик консультация бирүче юристлар үз максатларын ачык күзаллый.

«Ярдәм» фондының укыту-тернәкләндерү үзәге тарафыннан шулай ук экскурсияләр һәм спорт чаралары оештыру, йорт эшләренә өйрәтү кебек сабаклар үткәрү, паркларга, мәдәни чараларга алып бару да каралган. Проект кысаларында Казан шәһәрендә баннерлар урнаштыру, әйләнә-тирәбездә безнең ярдәмгә мохтаҗ кешеләр барлыгын искәртү дә планлаштырыла.

■ **dumrt.ru**

Хәмер куллану – шайтан гамәлләреннән

Интернетка кереп, берәр төрле эзләү системасында алкоголь дип җыя башласаң, ул төрле вариантлар тәкъдим итә. Әмма алар арасында иң еш очраганнары «алкоголь – зыян», «алкоголь – авыру», «алкоголь – ничек ташларга» дигән җөмләләр була. Чыннан да, алкоголизм – күп дәверләр буе дәвам иткән бер авыру. Аңа гади күренешкә караган кебек карарга ярамый. Ә иң мөһиме, бүгенге көндә ул татарлар көнкүрешенең бер өлеше буларак кабул ителә башлады: туган көннәрдә, кункалар кайткач, туйларда хәмерне еш очратырга була.

Кабаттан интернет челтәренә игътибар итик: Россия галимнәре 2000 еллардан алып, берничә ел рәттән һәлак булучыларның кан анализларын алып, тикшереп барганнар. Ни сәбәпле генә вафат булмасыннар: йөрәк өянәге, суга бату, юл һәлакәтенә эләгү – өчтән беренең канында хәмер табылган. Бу күбрәк 20 яшьтән алып 55 яшькә кадәр булган ир-атларда күзәтелгән. Күрсәткечләр россиялеләрнең хәмерне күп кулланганы турында сөйләсә дә, аны халыкның бер гадәте, дип кабул итәргә тиеш түгелбез. Алда ук әйтелгәнчә, бу – бары тик авыру гына һәм аны дәвалау юлларын эзләргә кирәк.

Ислам дине хәмер куллануны катгый тыя. Әгәр дә безнең илгә дә Ислам кануннарының бер-икесен генә урнаштырып булса, бу проблема акрынлап кына чишелеш ягына борылыр иде.

Әмма бу проблема вирус кебек бар дөньяны биләп алган. Европага күз салсак, аның кайбер илләрендә пиво эчү – күркәм гадәт булып санала: урамда булсынмы, кафеларда булсынмы, олысыннан – кечесенә, ир-аттан алып, хатын-кызга кадәр пиво тотканнар.

Америка Медицина Берләшмәсе хәбәр итүенчә, Америка хастаханәләрендә 20-45% кадәр кеше хәмер аркасында килеп чыккан авырулардан дәваланалар. Шулай ук хәмер – Америка юлларындагы һәлакәтләрнең иң төп сәбәпчесе икән. Гаилә таркалу, яңадан-яңа авырулар пәйда булу, үз-үзеңә кул салу кебек күренешләрнең күбесендә хәмер дә зур роль уйнаган. Шулай ук америкалыларның да яшәү рәвеше хәмер белән бәйле, дип әйтергә ярамый. Безнең халыкның да, аларның кулларыннан да хәмерне алып куюга, анда да, бездә дә бик күркәм кешеләр яши, дип әйтеп була. Һәм бу шулай да.

Дөньяга тумаган бала да бу проблемадан имин түгел. Бала ана карнында ук ата-анасының хәмер кулануыннан зыян күрә ала. Баланың, иң беренче чиратта, баш миенә зыян килә икән. Шулай ук тән төзелешендә дә кайбер үзгәрешләр булырга мөмкин. Сау-сәламәт бала табырга теләгән ата-аналарга хәмердән бер-ничә айга булса да баш тартып торырга киңәш ителә. Әмма бер кабул иткән хәмер организмнан озак вакытлар чыкмаска, яки, гомумән, ананың бәрәр эчке органына зыян салырга мөмкин. Шуңа күрә хәмердән гомумән баш тарту дөресрәк булачак.

Аллаһы Тәгалә дә: **«Әллә тыелмыйсызмы? Әлбәттә тыелыгыз!»** – дип әйтә.

Үз-үзеңә кул салу, кеше гомерен алу, гаиләләр таркалу, кешеләргә зыя салу, вандализмнар һ.б. шуның ише күп гамәлләрнең башында, гадәттә, хәмер тора. Әмма мөселманнар яшәгән җирдә мондый төр гамәлләр бик сирәк очрый, яки гомумән булмый. Әгәр алкоголизм авыру булса, мөселманнарның бу авыруга карата бик көчле иммунитетлары бар дип санарга кирәк. Әмма бу авыру:

– интернет, радио, телевидение аша рекламалана;

– ил буйлап ирекле рәвештә тарала ала;

– сатылган кибетләргә бик күп керем кертә;

– организмда авырулар пәйда булуга китерә;

– гаиләләр таркалуга;

– җинаятьләр саны артуга сәбәп була.

« Ий мөэминнәр! Исерткеч эчемлекләр һәммәсе, отыш уеннарның һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт итү, шулай ук ырымлану, багучылык – шайтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер. Саклансагыз, шаять, котылырсыз, өстенлек табарсыз. Хәмер эчүегез һәм отыш уеннары уйнавыгыз белән, әлбәттә, шайтан арагызда дошманлыкны һәм бер-берегезгә ачуны булдырырга; Коръән вәгазеннән, намаз укудан сезне тыярга тели. Әллә тыелмыйсызмы? Әлбәттә тыелыгыз!»

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:90-91

Хәмер – бозыклыкның анасы

Беркөнне пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм мәчеттән чыгып килгәндә, ул Гали бине Әбү Талибне очрата. Галинең йөзендә нуры качкан була һәм Пәйгамбәребез моны күреп, сәбәбен сорый. Гали җавап итеп, һәлак булган дөясенә генә күрсәтә. Бу дөя Галинең якын дустына әйләнгән була, чөнки бөтен походка да ул аның белән чыга. Гали дөянең вафатында Мөхәммәднең диндә булмаган бер агасы гаепле булырга тиеш, дип әйтә. Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең агасы янына килеп, аның фикерен тыңларга була. Һәм ни хикмәт, ул аны исерек килеш күрә. Энекәшен күргәч, ул Мөхәммәднең вафат булган дөя аркасында килгәнен аңлап ала, әмма акланыр өчен бер генә сүз дә таба алмый. Шуннан соң Пәйгамбәребез галәйһиссә-ләм: «Хәмер – һәр бозыклык-ның анасы», – дип җавап кайтара.

Пәйгамбәребез бу хәдисе белән хәмернең бик күп бозыклыклар тудырырга сәләтле булуын ассызыклый. Һәм аның бу агасына әйткән сүзләре һәрберебез өчен дә мөһим дәрес булып торырга тиештер. Кыска гына бу вакыйгада да бик күп гыйбрәт ята: исерек кеше берәр гамәлен ни өчен кылганын аңлата алмый; хайваннарга зыян салу проблемасы һ.б. Ә бу вакыйгага карасак, ислам дөньясы күп походлар белән сыналган дөясез дә калды дип әйтергә була. Шуңа күрә дә, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм хәмерне бүтән явызлыкларны тудыручы ана, дип атагандыр.

Күп кенә танышлар хәмернең рөхсәт ителгән күләмен сорап язалар, шалтыраталар. Ислам динендә исерткеч эчемлекләр бик аз күләмдә дә тыелган. «Күп күләмдә исерүгә китерә торган эчемлек аз күләмдә дә тыела» (Имам Тирмизи, Әбү Давыд, Ибне Мәҗәһ).

Ислам, чыннан да, кешене төрле яктан сәламәт булуы өчен көрәшә. Мөселман рухи яктан да, физик яктан да камил һәм сәламәт булырга тиеш. Шуңа да ислам кешенең акылын каплый торган, кешене исертә торган бер генә әйберне дә рөхсәт итми. Ә мондый эчемлекләргә һәр кешенең реакциясе төрле булачак. Кемдер күп кулланып та, аңа бернәрсә дә булмаячак, кемдер аз гына кулланып та, үзенең ни кылганы өчен җавап тота алмаячак. Шуңа күрә исламда минималь рөхсәт иткән күләм юк – ул нольгә тигез.

Әлбәттә, дөньяви өлкәдә генә эшләгән табиблар арасында да, гади халык арасында да хәмерне сәламәтлеккә файдалы, дип табучылар бар. Мәсәлән, ул тәнгә йомшарып китәргә, кешегә кыюырак булырга ярдәм итә, дип әйтәләр. Әмма изге Коръән Кәримгә игътибар итсәк, анда:

«Ий Мөхәммәд галәйһиссәләм! Синнән хәмер һәм отыш уены хакында сорашалар. Әйт: «Ул нәрсәләрдә зур гөнаһ бар һәм кешеләргә аз гына файдасы да бар, ләкин файдасына караганда гөнаһы һәм зарары зуррак... Әнә шулай Аллаһ сезгә үзенең аятьләрен ачык бәян итә, шаять, фикерләп карарсыз һәм аңларсыз!» – дип әйтелә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:219

Кешенең иминлеген күздә тотып, Ислам дине хәмерне ясауны да, аны бер урыннан икенче урынга күчерүне дә, сатуны да тыя. Һәм, әлбәттә, Коръәндә дә, хәдисләрдә дә хәмер белән эш иткән кешегә Кыяматтә газап булачагы турында бик күп искәртелгән. Бу эшләрне эшләгән кешегә тәүбә кыларга һәм бу эшкә бүтән әйләнеп кайтмаска тәкъдим ителә.

Хәмер һәм аңа охшаш гамәлләр – шайтан гамәлләреннән. Ә хәмер – барлык явызлыкларның, барлык бозыклыкларның анасы да булып тора. Аллаһы Тәгалә бу гамәлләрдән безне ерак кылса иде.

■ **Габделхәким Фәсхиев**

Зөлхиҗҗә ае якынлаша

Ин шә Аллаһ, 12 августтан зөлхиҗҗә ае башлана. Зөлхиҗҗә аеның атамасы «хаҗ» сүзеннән алынган. Ул мөселманнар өчен изге, ислам диненең биш баганасының берсе булган хаҗ сәфәре кылына торган ай булуга ишарә итә. Мөселманнар өчен әлеге ай аерым мәгънәгә ия һәм аңа аерым әһәмият тә бирү кирәк, чөнки ул һиҗри календарьның соңгы ае. Ул тулы бер елга йомгак ясый, яңа елга кергәндә чистарыну, гөнаһлардан арыну, тәүбә кылу, яңа планнар кору ае. Аллаһы Тәгаләнең безгә җибәргән бер рәхмәте-бәрәкәте бу: ел изге хаҗ кылына, корбан чалына торган зөлхиҗҗә ае белән тәмамлана. Игелек кылыйм дигән кешегә бәрәкәте, әҗер-савабы әйтеп бетергесез күп. Ислам динендә аерым айлар, мисал өчен, раҗәб, мөхәррам, зөлкагъдә айлары, аннан соң килә торган зөлхиҗҗә ае хәрам айлардан санала. Бу айларда гыйбадәтләребезне арттырырга, саваплы гамәлләрне күбрәк кылырга кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

«Җирне һәм күкләрне яраткан көннән бирле Аллаһ хозурындагы китапта айлар саны унике, ул унике айдан дүртесе хәрам айлар: ягъни раҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам айлары. Ул дүрт айда үзегезгә золым кылмагыз, бер-берегезгә ярдәмдә булыгыз, ташламагыз! Белегез, Аллаһ тәкъвалылар белән».

«Тәүбә», 9:36

Мөселманнар исә изге айларда, көннәрдә, кичәләрдә күбрәк вакыт намазда булырга, сәдака бирергә, Аллаһны зикер итергә тырышалар. Бу сәбәпле җәннәткә якынаялар, шайтаннан ерагаялар. Нәкъ менә шул рәвешле Аллаһка омтылган мөселманнар өчен зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне иң кулай мөмкинлек. Бу турыда Пәйгамбәребез галәйһиссәләм болай дип әйткән: «Аллаһ бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрдә кылынган игелекле эшләргә караганда ныграк ярата». Әгәр дә сәүдәгәргә: «Менә шундый вакыт җитә: 10 көн эчендә сез 1 еллык ризык, товар җыеп куя аласыз», – дисәләр, ул алдан ук бөтен акчасын әзерләп куячак, билгеләнгән көннәрне, бөтен эшен ташлап, товар җыюга гына багышлаячак. Соңыннан җиңел, рәхәт яшәр өчен шушы 10 көнне кулыннан ычкындырмаячак. Әйдәгез, без дә Аллаһ биргән мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйк. Рухи үсеш юлында киләсе 12 айга җитәрлек күләмдә бәрәкәт, савап җыеп калыйк. Ибне Габбас радыйаллаһу ганһү Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең түбәндәге хәдисен китерә: «Расүлүллаһ галәйһиссәләм зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне хакында: «Изге һәм саваплы гамәлләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан аеруча яратып кабул ителгән бу ун көннән дә хәерлерәк башка көннәр юктыр», – дип әйтте».

Әлеге көннәрнең бөеклеген раслау өчен Коръәнгә күз салыйк. Изге Китапта Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

«Ун төн белән ант итәм, ун төннәр зөлхиҗҗә аеның әүвәлге ун төннәредер, яки Рамазан аеның ахыргы ун төннәредер!»

«Фәҗер /Таң», 89:2

Галимнәр әлеге сүрәгә таянып, зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне фазыйләтләрен Рамазан аеның соңгы ун көнлеге белән чагыштыралар. Бу көннәр Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәте, рәхмәте белән тулган көннәр.

Үзенең хәдисләренең берсендә Пәйгамбәребез: «Аллаһ юлында тоткан бер көн ураза Аллаһ колының йөзен җәһәннәм утыннан җитмеш еллык ераклыкка читләтер», – дип әйткән. Зөлхиҗҗә ае башлану белән нәфел уразасын тотабыз. Ул 9 көн дәвам итә. 9 нчы көн – Гает алды көне Гарәфә көне дип атала. Ул көн дә мөбарәк көннәрдән санала. Гарәфә көнендә ураза тоту бик күркәм һәм саваплы булыр. Хаҗ гамәлләре дә шул вакытта үтәлә. Һәр елны дөньяның барлык илләреннән җыелган берничә йөз мең хаҗи Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында дога һәм гыйбадәт кыла.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм хаҗның кабул булуын Гарәфә көне белән бәйләгән. Хәдисләрдә Гарәфә көне ничек узса, ул көнне кылынган гыйбадәтләрне Аллаһы Тәгалә ничек кабул итсә, аның хаҗы да шулай кабул булыр, дип килә.

Гарәфә көнендә бирелә торган тагын бер зур бүләк – ураза тоту. Әгәр дә без зөлхиҗҗә аеның беренче көненнән 9 нчы көненә кадәр ураза тота алсак, бу тагы да фазыйләтле. Мөслим җыентыгында китерелгән хәдистән күренгәнчә, Аллаһ илчесе галәйһиссәләмнән Гарәфә көнендә ураза тоту хакында сораганнар. Ул: «Әлеге көндә ураза тоту үткән елгы һәм киләсе елгы гөнаһларның кичерелүенә сәбәп була», – дип җавап биргән. Димәк, Гарәфә көнендә тотылган бер көн ураза ике еллык гөнаһларны кичерерлек дәрәҗәдә саваплы булып чыга. Әйдәгез, мөселман кардәшләр, әлеге мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйк. Бу көнне Аллаһы Тәгаләгә тәкъвалылыкта, гыйбадәтнең ихласлыгында ярышыйк.

Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне турында сөйләгәндә тагын бер мәсьәләне читләтеп үтәргә ярамас. Мөселманнар өчен атна саен тырнак кисү һәм чәч-сакал кыскарту сөннәт гамәл санала. Әмма зөлхиҗҗә аеның беренче ункөнлегендә бу гамәлләрне читкә куеп торсак яхшырак булыр. Аллаһы Тәгаләнең сөекле колларының берсе Әбү Хәнифә бу уңайдан болай дигән: «Зөлхиҗҗәнең беренче ун көнендә әлеге сөннәтне калдырып торсагыз хәерлерәк. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең: «Корбан чалырга җыенган кеше зөлхиҗҗә ае керүгә тырнагын да, чәчен дә кисмәсен», – дигән хәдисе катгый күрсәтмә түгел. Әмма шулай да әлеге гамәлләрне Корбан чалынганнан соң гына үтәү мөстәхәб саналыр».

Димәк, корбан чалырга ниятләгән кешегә, хаҗиларга охшау йөзеннән, чәч, сакал, мыек кыскартмау, тырнак кисмәү мөстәхәб гамәл саналыр. Әмма бу гамәлне вәҗиб, ягъни мәҗбүри дип санау дөрес түгел. Тырнагын яки чәч-сакалын кискән кеше гөнаһлы булмас, аның Корбан чалуының савабы да кимемәс, ин шә Аллаһ!

Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнендә кылынырга мөмкин булган иң саваплы гамәл – хаҗ сәфәрендә булу. Аллаһы Тәгалә әлеге изге гамәлне гомердә бер тапкыр булса да кылырга насыйп итсен иде, чөнки хаҗ сәфәренә барган, андагы барлык йолаларны тиешле дәрәҗәдә үтәгән мөселманнарга Аллаһы Тәгалә гаҗәеп дәрәҗәдә әҗер-саваплар әзерли. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең бер хәдисендә: «Кабул кылынган хаҗның әҗере җәннәт нигъмәтләренә тиңдер», – дигән.

Аллаһы Тәгаләадәм балаларының изге юлда булуын, аларның саваплы гамәлләр белән яшәвен хуп күрә. Шуңа күрә Аның рәхмәтенә ирешү өчен, хаҗга ниятләргә кирәк. Изге сәфәргә барам, дип ният кылган мөселманга Аллаһы Тәгалә акчасын да, җаен да, яхшы юлдашын да насыйп итә. «Изге ният – ярты гамәл» дигән мәкальне ишеткәнегез бардыр. Хаҗ кылу мөмкинлеге булмаган очракта да, көннәребезне гамәл-гыйбадәттә үткәрергә тырышсак иде.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне, фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!»

«Кәүсәр» , 108:2

Корбан чалырга теләүчеләр бу изге гамәлне башкарырга алдан ук әзерләнә башлый. Аллаһы Тәгалә мөмкинлеге булган һәр кешегә Корбан чалуны фарыз итә.

Бу уңайдан Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Аллаһы Тәгалә каршында иң бөек көннәр булып Корбан бәйрәме һәм Әл-Карр көннәре тора», – дигән. Әл-Карр көне — зөлхиҗҗә аеның унберенче көне, ул гарәп теленнән тәрҗемә иткән вакытта — «урнашу, булу»ны аңлата, чөнки хаҗ кылучылар бу көнне хаҗ кылуның бар йолаларын да башкарып бетереп, Мина үзәнендә булалар.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм үзенең кызы Фатыйма радыйаллаһу ганһәгә: «Корбан чалдыр, чөнки корбан канының тамган беренче тамчысы ук гөнаһларның ярлыкануына сәбәп булыр. Кыямәт көнендә исә ул корбан ителгән хайванның мөгезләре, тиресе, әгъзалары, йоны һ.б мизанга салынып, барча гөнаһлардан да авыррак булыр. Корбан ителгән хайванның һәрбер бөртек йоны өчен 40 мең әҗер-савап язылыр», – дип әйткән.

Әбү Сәгыйть Әл-Хөдри радыйаллаһу ганһү исемле сәхабә Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән: «И Аллаһ илчесе! Бу эштән хасил булган әҗер-саваплар синең йорт әһеленә генә хас булырмы, әллә барча мөэмин-мөселманнарга да кагылырмы?» – дип сораган. Пәйгамбәребез: «Өммәтемнән һәркем корбан чалса, ул кешегә бу әҗер-саваплар һәммәсе дә бирелер»,–диде. Корбан итенең өчтән бер өлеше туганнарга, күршеләргә өләшенергә тиеш. Өчтән бер өлеше мохтаҗларга, калган өлеше гаилә әһелләренә кала. Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә, Корбан гаетендә кылынган гыйбадәтнең әҗер-савабы исә гаят зур булган кебек, гөнаһ өчен дә газап зур булачак.

Шулай итеп, бер зөлхиҗҗә ае өчен генә дә бик күп гыйбадәтләр җыела. Ул –гает намазы, ураза, хаҗ, корбан чалу, сәдака бирү һәм башка бик күп төрле гамәлләр. Бу – Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән мөмкинлеге һәм бу форсатны кулдан ычкындырмасак иде!

■ **МДН Дәгъват бүлеге**

Аллаһы Тәгалә күп тапкыр зина кылучыны кичерәме?

Сорау: Кеше аңлы рәвештә бик күп тапкыр зина кылса да, Аллаһтан гафу сорарга хакы бармы? Аның бу гөнаһы ярлыканамы?

Җавап: Зина – бик зур гөнаһ. Әгәр дә кеше зина кылып, дөньядан тәүбә итмичә үтсә, Ахирәт тормышында бик авыр газапларга дучар булуы мөмкин.

«Мәгәр берәү тәүбә итеп, иман китерсә һәм Коръән юлы белән изге гамәлләр кылса, әнә шундый кешеләрнең начарлыкларын яхшылыкка алмаштырыр, Аллаһ андыйларга ярлыкаучы вә рәхмәт кылучы булды».

«Фуркан / Аеручы», 25:70

Бу гөнаһ Ахирәт тормышына гына түгел, бу дөньяга да тискәре тәэсир ясый: гаиләләр таркалуга, никахсыз балалар тууга һ.б. сәбәп була.

«Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш вә бик яман, кабахәт юлдыр».

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

Шулай ук Пәйгамбәребез галәйһиссәләм дә: «Берәр халыкта зина таралса, ул халыкта чума (йогышлы авыруы) һәм яңа авырулар таралыр», – дип әйткән (Ибне Мәҗәһ).

Шуңа күрә, кеше нинди генә гөнаһ кылса да, ул беренче эш итеп тәүбә кылып, Аллаһка итагать итү юлына кайтырга тиеш.

«Аллаһ үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны үзе теләгән кешедән гафу итәр».

«Нисә / Хатыннар», 4:48

« Ий мөэминнәр, Аллаһка ихлас тәүбә итегез, Раббыгыз сезнең яманлыкларыгызны каплар һәм асларыннан елгалар ага торган җәннәтләргә кертер. Ул көндә Аллаһ Пәйгамбәрне вә иман китереп, Пәйгамбәр белән бергә булганнарны хур кылмас, аларның нурлары алларыннан вә уңнарыннан йөрер. Алар: «Ий, Раббыбыз, безгә нурыбызны тутырып бир һәм гөнаһларыбызны ярлыка, тәхкыйк, Син һәрнәрсәгә кадирсең!» – дип әйтерләр».

«Тәхрим / Тыю», 66:8

Аллаһы Тәгалә тәүбәне кабул кылсын өчен, ул тәүбә чын, ихлас күңелдән кылынган булырга тиеш. Кеше нинди генә гөнаһ кылмасын, ул, барыбер, тәүбә кылырга ашкынырга тиеш. Гөнаһы өчен борчылу хисләре булса, димәк, кеше үз кылган гамәле өчен чыннан да үкенә. Ә инде зина кылудан туктау юлы – никах. Аллаһы Тәгалә никах аша ир белән хатын-кыз мөнәсәбәтләрен хәләл итеп кылды.

■ **islam-today.ru**

Коръән укыган өчен савапны югалтмагыз



Сорау: Коръәнне тулысынча укып чыгуның (хәтем кылуның) нинди өстенлекләре бар? Хәтемнән соң нинди дога кылырга була?

Җавап: Мөселман кешенең бар максаты – һәрбер гамәлдә дә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга тырышу. Моңа Аллаһ Үзе урнаштырган кагыйдәләргә һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәләм сөннәтенә иярү ярдәмгә килә. Шундый изге гамәлләрнең берсе булып хәтем чыгу тора.

Хәтем – Коръәнне тулысынча укып чыгу. Коръәнне укыгач «Хәтем догасы» кылына. «Суюути Җәмигүс-сәгыйр» китабында түбәндәне хәдис китерелә: «Кем Коръәнне тыңлау, уку, кабатлау аркасында хәтем чыга, махсус догасын да уксын». Пәйгамбәребез Мөхәммәд Коръәнне тулысынча укып чыкканнан соң, һәрвакыт дога кыла торган булган.

Имам Куртуби болай дип әйткән: «Кахем бине Гүтәйбә Коръәнне укып чыкканнан соң, бер төркем кешегә: «Без Коръәнне укуны тәмам кылабыз, шуңа күрә сез дә безнең белән бергә булыгыз. Дөреслектә, Бу Аллаһтан нигъмәтләр иңә торган вакыт,» – дип әйтә иде».

Хәтем кылганнан соң кылына торган догалар:

«Садәкаллаһуль-газыйм. Вә бәлләга Расүлүхуль-кәрим. Вә нәхнү галә зәликә минәш-шәәһидин. Раббәнә әәмәннә бимәә әңзәлтү вәттәбәгънәр-Расүүлә фәктүбнә мәгәш-шәәһидин».

Тәрҗемәсе: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә хак юлны күрсәтте. Расүлүллаһ галәйһиссәләм безгә аны ирештерде. Һәм без моңа шаһит булып торабыз. Ий, Раббыбыз, син индергән китапларга ышандык һәм Пәйгамбәргә иярдек. Безләрне Синең берлегең вә исламның хаклыгы белән шәһадәт бирүче мөселманнар белән бергә кыл!»

«Сөбхәнә Раббийәл-галийил-әгъләм әл-вәһһәәб».

Тәрҗемәсе: «Чиксез Бүләкләүче, Бөек һәм бөеклеккә Ирештерүче Раббыма мактау булсын».

Шулай ук бер хәдистә: «Пәйгамбәребез хәтем догасы кылыр алдыннан «Нәс», «Фәтихә» сүрәсен һәм «Әл-Бәкара» сүрәсенең беренче 5 аятен укый торган иде», – дип әйтелә. Кабаттан «Фәтихә» сүрәсе укылгач, Коръән китабы беренче битләре белән өскә кала һәм бу күркәм бер гадәт булып санала. Коръәнне укып бетергәч, Аллаһы Тәгаләдән үзегез өчен хәерле догалар кылырга мөмкин.

■ **islam-today.ru**

Аренда вакытындагы дәгъвалар

Сорау: Бүгенге көндә бөтен кеше дә үзләренә фатир сатып ала алмыйлар. Шуңа күрә фатирны арендага бирү киң таралды. Әгәр бу эш барышында каршылыклар килеп чыксa, дәгъваны ничек чишәргә?

Җавап: Мәсьәләнең чишелеше каршылыкның кайсы вакытта килеп чыкканыннан да тора:

1. Әгәр аренда барышы башланганчы ике тараф арасында ихтиләф килеп чыксa, икесе дә сүзләрен дөресләп ант итәләр һәм килешү юкка чыгарыла.

2. Әгәр ике тараф аренда барышында каршылыкка килсәләр, дәгъва арендачы файдасына чишелә. Әгәр ул сүзен дөресләп ант итсә һәм моннан соң аренда килешүе юкка чыгарылса, ике тараф та үзләренең хаклы булуларын раслап ант итәргә тиеш булалар.

3. Әгәр ике тараф та аренда вакыты тәмамлангач каршылыкка килсәләр һәм арендачы үзенең дөреслеген раслап ант итсә, дәгъва аның файдасына чишелә.

■ **«Әт-тәсhил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан**

«Ислам һәм татар дөньясы» Концепциясе онытылып барамы?»

Ислам һәм татар дөньясы... Моннан биш ел элек шушы исемдә бөтен татар халкы өчен нигезле документ кабул ителә. Татарстан үзе өчен иҗтимагый, икътисади-сәяси юнәлешләрен билгеләгән иде инде, ә менә аның рухи үсеш үзенчәлекләрен һәм юлларын нәкъ менә «Ислам һәм татар дөньясы» концепциясе ачыклап күрсәтә.

Бу мөһим документта нигездә дини илаһият һәм социаль мәсьәләләр урын алган. Концепциядә традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалауга, татар халкының рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрен, бөек татар галимнәре һәм узган гасырларның дин әһелләре мирасын саклауга зур игътибар бирелә.

Әйтергә кирәк, бу стратегия – имамнар, галимнәр, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләре, әйдәп баручы шәхесләрнең, милли һәм рухи лидерларының уртак хезмәт җимеше. Шуңа күрә мөфтиятебез башкарган эшнең һәм башлангычларының муафыйклыгында, чыгарылган теге яки бу карарларның мантыйклыгында шикләнеп, фетнә кабартып, бәхәс чыгаручылар мине гаҗәпләндерә. Аларга бер генә сорау бирәсе килә: сез «Ислам һәм татар дөньясы» Концепциясе белән танышмы соң? Укучыларга уңайлы булсын өчен үземнең мәкаләмдә мин шушы күләмле документтан кайбер мөһим өлешләрне кыскартып китерәм. Сез күрерсез: андагы тезислар бүгенге көн өчен актуаль, дип кенә әйтү дә дөрес булмас, алар үз әһәмиятен мәңге югалтмаячак!

Мәзһәб мәсьәләсе

Мисал өчен, «Хәзерге заман татар-мөселманнары динне эзәрлекләү елларын үз башларында кичерүгә карамастан, аннан «чиста» Ислам таралуына карамастан, матуридилар булып калуын дәвам итәләр, һәм аларның ата-бабалары сөнни – Ислам күзлегеннән караганда дөрес юлда булган, аңлы рәвештә хәнәфичелек һәм матуридичелек юлын сайлаган дип аңлыйлар», — диелә документта. Күргәнегезчә, татарлар арасында дин мәсьәләсендә башка бернинди агымнар турында сүз бармый. Хәнәфилек, башка мәзһәбләрдән аермалы буларак, күпмилләтлелек һәм күпдинлелек шартларында формалашканга күрә, Россиядәге чынбарлыкка, мондагы көнкүрешкә иң тулы рәвештә туры килә торган мәктәп булып кала бирә. Соңгы вакытта еш кына кешеләрне аларның карашлары өчен эзәрлекләү турында ишетелә. Шул нисбәттән Концепциядә, алдан белгән шикелле, ап-ачык фикер китерелә: «Әгәр дә карашлары җәмгыятькә, аның иминлегенә зыян китерми икән, кешеләрне аларның карашлары өчен тәнкыйтьләргә ярамый». Шул ук вакытта документ мондый нәтиҗә чыгара: «Татар-мөселманнар арасында аңлашылмаучанлык, тавыш-гауга, каршылыклар китереп чыгармас өчен, хәнәфиләр мәзһәбен тотарга кирәк. Шул ук вакытта, йола-кануннарны үтәгәндә бер мәзһәбне тану, татар-мөселманнарны бергә туплаячак һәм ул аларның берлеге билгесе булачак».

Бәхәсле сорауларга урын бармы?

Ел саен татар мөселман өммәтендә бер үк сораулар туа: Мәүлид һәм Сабантуйны уздыру һәм исламга бернинди катнашы булмаган милли гореф-гадәтләрне үтәү дөресме? Бу хакта да Концепция безгә җавап бирә: «Шәригатькә каршы булмаган, Исламны кабул иткәч тә татарлар тарафыннан үтәлеп килгән исламгача яшәгән традицияләр, Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча гореф-гадәт өлкәсенә караган гамәлләр буларак рөхсәт ителә. Дингә һәм акыл эшчәнлегенә каршы куелмаган гореф-гадәт, йола-кануннар, Шәригать өчен дөрес дин табыла һәм хупланыла. Коръән үзе хокукның бу чыганагын дәлилли: **«...Аллаһтан куркыгыз, аның хөкемнәренә хыйлафлык кылудан сакланыгыз! Яхшы белегез, Аллаһ сезнең кылган эшләрегезне күреп күзәтүче»** (2:233). Шәригатькә нигезләнгән мөселман гореф-гадәтләре һәм билгеле бер дини гамәлләр, дингә яңалык кертү (бидгать) дип исәпләнә алмыйлар. Шуңа күрә, дәгъват гыйлеме ягыннан караганда, әйтик, Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең туган көнен, Мәүлидне, әти-әнисе Габдуллаһ белән Әминәнең никахлашу көнен – Рәгаибне бәйрәм итү, вафат булганнар рухына багышлап аерым аятьләр һәм догалар уку, ашлар үткәрү, догалык белән бөти тагу, дисбе куллану, Коръән мәҗлесләре җыю, изгеләрнең каберенә зиярәт кылу кебек гамәлләрне тыярга яисә аларны дингә яңалык кертергә тырышу, дип санарга ярамый. Мондый бәйрәмнәр вакытында Аллаһы Тәгалә Үзенең мөэминнәренә аерым бер рәхимшәфкатен ача.

Суфичылык – сектамы?

Документта суфичылык үсеше мәсьәләсе дә каралган: аны гаделсез рәвештә бүген секталар белән чагыштыралар һәм аңа Татарстанда урын юк, дигән фикерне алга сөрәләр. Югыйсә, традицион суфичылык мәктәбе экстремизм һәм радикализмга каршылык күрсәтүдә, кешелеклелек идеяләрен һәм мәдәниятләр арасындагы үзара аралашуны ныгыту эшендә зур көчкә ия. Суфичылык – Россиядәге традицион исламның аерылгысыз бер өлеше. Суфичылыкның бай гореф-гадәтләре Идел буе һәм Төньяк Кавказның мөселман халыкларына бик хас. Зәйнулла ишан Расүлев, имам Шамил, Шиһабедтин Мәрҗани, Тажетдин Ялчыгол, Мәхмүт әфәнде, Габдерәхим Утыз-Имәни, Галимҗан Баруди, Курсави һ.б. – болар Россия суфичылыгының бөек галимнәр йолдызлыгына кергән берничә исем генә! Суфичылык яшьләр өчен чып-чын альтернатива булып тора алыр иде, чөнки аның идеяләре сабырлыкка, башка дин әһелләренә карата ачык мөнәсәбәткә, бер-береңә хөрмәткә чакыра. Болар исә кешелек кыйммәтләренең төп өлеше һәм рухи тәртип һәм хәйриянең чыганагы булып тора.

Милли сорау

Концепция милли сорауга карата да тулысынча дини алымны чагылдыра. Төп принцип булып биредә «илаһи күзаллау концепциясе» тора: Аллаһы Тәгалә тарафыннан булдырылган һәрнәрсә кеше тырышлыгы белән генә үзгәртелә алмый, димәк, кешеләрнең «кабилә һәм халыклар» берләшмәсе мәңгегә һәм үзгәрешсез калачак. «Татар җәмгыятендә милли идеяләр ислам белән бик тиз берләшә һәм диннең позициясен ныгытуга ярдәм итә һәм бер үк вакытта милли мәдәниятнең иммунитетын көчәйтә». Шул сәбәпле, ТР мөселманнары Диния нәзарәте үз өстенә татар халкының милли тәңгәллеген саклап калу миссиясен алды.

Концепциядә төгәл язылган: «Дөньяви дәүләтне динсез дәүләттән аера белергә кирәк. Дөньяви дәүләт төрле дини берләшмәләр хезмәттәшлек итә ала һәм мөэминнәргә ярдәмгә омтыла». Күп милләтле һәм күпконфессиональ республика һәм ил өчен тагын нинди дәүләт төре булырга мөмкин?! Иҗтимагый киңлекнең дөньявилыгы Ватаныбыз гражданнары өчен уртак тормышны максималь рәвештә гадел һәм уңайлы итә.

Игелекле Коръән безнең карамагыбызга түбәндәге принципны бирә: **«Әй, мөэминнәр, Ходайга, пәйгамбәрләргә, Расүлебезгә итагать итегез»** (4:59), ягъни хакимияттә баш булучыларга итагать итү.

Хәзерге заман җәмгыятендә мультикультурализмны һәм башка дингә карата тискәре мөнәсәбәттә булу, мәдәни төрлелекне кабул итмәү Россиядә ислам үсешенә тоткарлыклар тудыру һәм нокта кую дигән сүз. «Мөселманнар иҗтимагый тормышка ияру өчен барлык тырышлыкларын куярга тиешләр, — диелә концепциядә. «(...) Бары тик конкуренциягә каршы торырлык, сынатмаслык карарлар Исламны хәзерге дөнья шартларында үсештә, уңышлы идеологиягә ирештерергә мөмкин».

Россиянең Идел-Урал территориясендә барлык мөселман руханилары татар дин әһелләре булу сәбәпле, үз эшләрендә «Ислам һәм татар дөньясы» концепциясен кулланулары алар өчен бик урынлы һәм файдалы булыр иде.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин**

Унберенче тапкыр Республикакүләм мөселман балалар Сабан туе узды

15 июль көнне Балтач районының Бөрбаш авылында Республикакүләм мөселман балалар Сабан туе узды. Бик күп кунаклар, хөкүмәт вәкилләре, дин әһелләре, күренекле шәхесләр катнашында уздырылган әлеге күркәм чара быел унберенче тапкыр Балтач районы имам-мөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның тырышлыгы белән оештырылды.

Сабан туена килүчеләрнең һәммәсе баш киеменнән – ир-атлар түбәтәйдән, хатын-кызлар яулыктан иделәр. Кунакларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразиев, ТР Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фондының башкаручы директоры Нурия Хәшимова, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы Рамил Нотфуллин сәламләде. Өйлә вакыты җиткәч җәмәгать белән намаз укылды.

Сабантуй балаларның Коръән һәм догалар укулары, мөнәҗәт әйтүләр, шигырьләр белән үрелеп барды.

Бәйрәм кысаларында балалар өчен төрле уеннар, ярышлар, рухи кыйммәтләрне барлаучы чаралар үткәрелде. Барлыгы төрледән-төрле 17 ярыш оештырылды. Моннан тыш, 35, 50, 65 килограммга кадәрге һәм аннан югарырак үлчәү категорияләрендә балалар арасында көрәш бәйгесе булды. Абсолют батырга скутер, башка җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр бирелде.

Россиядә тәүге тапкыр имамнар массакүләм рәвештә ГТО нормаларын тапшырды

Россиядә тәүге тапкыр имамнар массакүләм рәвештә ГТО нормаларын тапшырды. Татарстанның төрле почмакларында дини эшчәнлек алып баручы хәзрәтләр Чистайга җыелды. Очрашу урыны итеп бу шәһәрне сайлау очраклы түгел – ул республиканың нәкъ уртасында урнашкан һәм Татарстанның көнчыгыш белән көнбатышы кисешкән урыны булып тора. Җыелуның сәбәбе дә кызыклы. Биредә дин эшлеклеләре Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә тәүге тапкыр массакүләм рәвештә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы сынау нормативларын үтәү буенча тестларда катнашты. Көч, җитезлек һәм чыдамлылыкны тикшерүгә юнәлтелгән җиде сынау күнегүендә Татарстанның 48 шәһәре һәм районыннан килгән 80нән артык мөселман дин әһеле үзләренең физик әзерлекләрен тикшерде. Бу акция Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең иң зур спорт башлангыч-ларының берсе. Шундыйлардан тагын Мәрҗани исемендәге Кубокка джиу-джитсу буенча Бөтенроссия турнирын һәм ТР МДН кубогына көрәш һәм кул көрәше Республика ярышларын атап үтик.

Дин әһелләренең физик әзерлекләрен тикшерү Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фикере белән оештырылды. Актив һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау ТР Диния нәзарәтенең яшьләр сәясәте һәм дәгъват бүлегенең аерылгысыз бурычларының берсе. Спорт чаралары яшь мөселманнар, шулай ук, традицион конфессия вәкилләре арасында берләштерү, дуслыкны ныгыту һәм үзара аңлашуның мөһим чарасы булып тора. Мондый сынаулар актив гражданлык позицияле шәхес формалаштыруга һәм башка дин вәкилләренә карата хөрмәт уятуга юнәлтелгән. Әлеге сынауларга яшь мөселманнардан тыш тәҗрибәле имамнар да кушылды. Алар Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең сүзләрен искә төшерделәр: «Раббыбыз тарафыннан көчле иманлы көчсез иманлыга караганда күбрәк яратылыр, икесендә изгелек булса да...» Бүген әлеге сүзләр «Татнефть олимп» спорт комплексында еш яңгырады.

Акциядә катнашучыларны һәм шәһәр кунакларын Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Чистай башлыгы Дмитрий Иванов һәм ТР ГТО региональ иҗтимагый оешмасының башкарма директоры Таһир Гыйзәтуллин сәламләде. Алар чарада катнашучыларга уңышлар һәм сәламәтлек теләделәр.

Үзләренең физик әзерлекләрен хәзрәтләр ГТО комплексының түбәндәге күнегүләре ярдәмендә тикшерделәр: иелү, баскан урыннан ераклыкка сикерү, яткан шәкелдән гәүдәне торгызу, кул белән җирдән этелү, кыска араны йөгерү. Имамнар алларында торган сынауларны уңышлы гына үттеләр. Чистай тест үткәрү үзәге хезмәткәрләренә нәтиҗәләрне йомгаклап ВФСК ГТО тест үзәгенә җибәрү генә кала. Чистайга килер алдыннан акциядә катнашучылар gto.ru сайтында теркәлде.

Бүгенге көндә Татарстанда ГТОның 51 тест үзәге һәм 356 тест үткәрү урыны бар. ГТО сайтында 560 мең Татарстанлы теркәлү узган һәм шуларның 300 000гә якыны инде нормаларны тапшыруга керешкән.

Имамнар арасында ГТО нормаларын тапшыру ел саен оештырылачак. Россиядә футбол буенча барган Дөнья чемпионаты уңаеннан имамнар арасында оештырылган конфессияара футбол матчы очрашуның кульминациясе булды. Дустанә матчта республика мөхтәсибләре һәм Чистай епархиясенең «Дуслык» һәм «Дружба» дип исемләнгән катнаш командалары уйнады.

■ **dumrt.ru**

Корбан чалу Аллаһка якынайта

Корбан бәйрәме (Гыйд әл-әдха) – хаҗ тәмамлануын белдерә торган Ислам бәйрәме. Ул Ураза бәйрәме тәмамлангач 70 көн узуга, зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә билгеләнә, мөселманнарның иң зур бәйрәме булып санала. Аллаһы Тәгалә ике пәйгамбәребезне зур сынау белән сыный. Ибраһим пәйгамбәр улы Исмәгыйльне корбан итәргә алып барганда, Аллаһның рәхмәтеннән сөрелгән шайтан аңа килеп вәсвәсә кылып: «Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач, тизрәк», – дип әйтә. Сөекле әтиәнисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга ияләшмәгән бала: «Мин Аллаһ әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли», – дип мәлгунне ташлар атып куып җибәрә.

Колларының итагатьләренә күрә, Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте итеп Исмәгыйльне саклап кала. Ата кешенең кулындагы пычагы үтми һәм Аллаһ тарафыннан күктән корбан итәргә дип, бәрән төшерелә.

Шул көннәрдән бирле изге бер йола итеп Корбан гаете билгеләп үтелә. Бу тарихи вакыйга барыбыз өчен дә бик мөһим һәм гыйбрәтле. Шул ук вакытта без бу кыйссадан Аллаһның киң кодрәтен күрә алабыз.

Безнең буынга әлеге бәйрәм төрле гадәт, әдәби әсәрләр аша килеп җиткән. Гадәттәгечә, ул Мәккәгә хаҗ кылу белән туры килә. Бәйрәм ир кешеләр өчен госел алып, чиста-пакь киемнәрне киеп, мәчеткә гает намазын уку өчен бару белән башлана. Гадәт буенча, мәчеткә барганда тәкбир – «Әллаһу әкбәр, Әллаһу әкбәр, лә иләәһә иллә ллаһү вә-ллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә-ли-лләһил-хәмд» – сүзләре әйтелә. Гает намазыннан соң корбан чалына. Аннан соң туганнарны, танышларны зиярәт кылу, табыннар әзерләү, бүләкләр тарату кабул ителгән.

Кемгә корбан чалу вәҗиб?

Корбан чалу кешегә мәҗбүри булсын өчен үтәлергә тиешле шартлар бар. Байлыгы һәм мөмкинчелеге булган һәрбер мөселман кешесе өчен корбан чалу вәҗиб гамәл санала. Быел корбан чалу өчен нисаб күләме 18 мең сум, дип билгеләнде. Ягъни, шушы күләмдәге акчасы булган кеше корбан чалырга тиеш.

Шулай ук бу эшкә тотынган кешенең акыллы, балигъ булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде кешенең корбан чалырга мөмкинчелеге юк икән, аңа гөнаһы да юк. Шулай да бу изгелекле эшнең әҗере бик бөек икәнлеген онытырга ярамый, чөнки корбан чалганда, хайванның беренче тамчы каны җиргә тамганчы ук суючының гөнаһлары кичерелә.

Бу гамәлдә, башкалардагы кебек үк, ният зур әһәмияткә ия. Аллаһы Тәгалә «Хаҗ» сүрәсенең 37 нче аятендә әйтеп үтә:

«Сез чалган дөяләрнең итләре вә каннары Аллаһка ирешмәс, мәгәр тәкъвалыгыгыз вә изге гамәлләрегез ирешер».

«Хаҗ», 22:37

Нинди хайванны корбанга чалырга ярый?

Корбан ителәсе хайванның кимчелекләре

булырга тиеш түгел. Әмма хайванның кайбер кимчелекләре булса, аны корбан итәргә була әле. Алар түбәндәгеләр:

– хайванның күз күреме начар булу, кылыйлык;

– бер аягы аксау, әгәр бу аксаклык хайванның йөрүенә комачау итмәсә;

– тумыштан мөгезләре яисә мөгезенең бер өлеше булмау;

– колаклары тишелгән булу;

– берничә теше булмау;

– койрыгының яки колагының зур әһәмияткә ия булмаган өлеше булмау.

Ләкин иң яхшысы – хайванның бу кимчелекләрдән пакь булуы.

Ә кайбер җитдирәк кимчелекләр аркасында хайваннар корбанга чалынырга лаек түгел. Алар түбәндәгеләр:

– бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булса;

– аксаклыгы берәр урынга барып җитәр өчен комачау итсә;

– бер яки ике колагы да тулысынча киселгән булса;

– күпчелек тешләре булмаса;

– бер яки ике мөгезе төптән сынган булса;

– койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булса;

– имчәкләре булмаса;

– бик талчыккан хәлдә яки хәлсез хайван булса;

– тумыштан колаксыз яки койрыксыз булса;

– көтүдәге калган хайвннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган булса;

– нәҗес (чиста булмаган ризык) белән тукланган булса.

Корбанга суелырга лаеклы хайваннар булып сарык, кәҗә, сыер, үгез, буйвол, дөя тора.

Ә калган хайваннарны корбан итеп чалу ярамый. Югарыда әйтелгән хайваннар ата җәнесеннән дә, ана җәнесеннән дә була ала. Нигездә сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар бер еллык булырга тиеш. Әгәр дә хайван ярты еллык, әмма көр, таза һәм бер еллык кебек булса, андый да ярый. Ә эре мөгезле хайваннар ике яшьлек, ә дөя биш яшьлек булырга тиеш. Эре мөгезле хайван белән дөя бер кешедән дә, җиде кешедән дә чалына ала. Ләкин бергәләп эре хайванны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһ ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Әгәр дә аралларыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул ителми.

Корбан чалу тәртибе

Корбан чалу рәвешен искә төшереп китик. Башта тыныч кына итеп корбанны чалынасы урынга алып килергә җиткерергә кирәк. Аннары газап кылмыйча, сул ягына яткырырга һәм башын кыйблага борып куярга кирәк. Вак мөгезле хайванның арткы уң аягыннан кала өч аягы да бәйләнә. Суясы кеше ниятен, янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Шуннан «Әл-Әнгам» сүрәсенең (162-163) аятьләре укыла:

«Әйт: «Дөреслектә, минем намазым, гыйбадәтем Аллаһка, яшәвем дә, үлемем дә Галәмнәрнең Раббысы ихтыярында, Аңа тиңдәшләр юк».

«Әнгам / Терлек», 6:162-163

Моннан соң «Бисмилләһ, Әллаһү әкбәр», дип хайван чалына. Һәм дога кылына.

Өстәмә рәвештә ике рәкәгать нәфел намазын укырга була. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Корбан чалган кеше пычагын куйгач та, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһ аңа ни теләсә шуны бирер», – дип әйткән.

Корбан ите ничек итеп таратылырга тиеш?

Корбан, нигездә, фәкыйрь, мохтаж, мескен, ятим, кимчелекле кешеләргә, тол хатыннарга, сәфәрдә булучыларга өләшенә. Әгәр дә корбан чалган кешенең үз әнисе тол хатын була икән, аңа да бирелергә тиеш. Корбанлык итен ике төрле юл белән корбан әһелләренә ирештерәләр. Берәүләр кисәкләргә бүлеп, итне тарата, икенчеләр, табын ясап, мохтаҗ кешеләрне чакырып, Коръән мәҗлесе үткәрә. Икесе дә күркәм гамәл булып санала. Һәм ничек эшләсәң дә, дөрес була.

Итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе – ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше чалучының гаиләсенә кала.

Корбан чалу, беренчедән, Аллаһка һәм Аның ризалыгына якынайта. Раббыбыз ул корбанга мохтаҗ түгел, тик Ул моның белән безнең Үзенә якынлык дәрәҗәсен тикшерә. Шулай ук корбан Исмәгыйь галәйһиссәләм кыйссасын искә төшерә, аның коткарылуы хакында фикерләвебезне яңарта. Мөселманнарның корбан чалуы – аларның Аллаһ юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландыруга китерә.

Ә корбанның файдасына килгәндә, кешенең гөнаһлары ярлыкана, ул Аллаһка шөкер итеп, Аның алдында булган бурычын үти, чалынган хайван Кыямәт көнендә чалучыны Сират күпере аша алып чыга һәм аның котылуына сәбәпче була. Мескен, ятимнәрне сөендереп, без аларның канәгатьләнүенә ирешәбез.

Гадәттә, без һәр елны көчебездән килгәнчә, гает бәйрәмен олылап үткәрергә тырышабыз. Күпләребез бу йоланы авылларына якыннары янына кайтып үти, ә менә андый мөмкинчелекләре булмаучылар шәһәребез мәчетләренә мөрәҗәгать итә ала. Быел Корбан гаете 21 август көненә туры килә. Корбанны 21, 22, 23 нче август көннәрендә чалырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә барча гыйбадәтләребезне кабул кылсын!

■ **Тимергали хәзрәт Юлдашев,**
Галиев мәчете имам-хатыйбы

Гарәфә көненең фазыйләтләре



Гарәфә көне – зөлхиҗҗә аеның тугызынчы көне. Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Хаҗ – ул Гарәфәт!» – дигән. Шуңа күрә тиздән Гарәфәт тавына менәчәк дин кардәшләребез өчен дога кылыйк, Аллаһы Тәгалә аларның хаҗларын кабул итсен, гөнаһларын кичерсен һәм безгәдә шул гыйбадәтне үтәргә насыйп итсен!

Гарәфә көнендә берничә сөннәт гамәлне үтәү хәерле санала.

1 сөннәт гамәл: Гарәфә көнендә ураза тоту – Пәйгамбәребезнең сөннәте булып тора.

Имам Мөслим тапшырган сахих хәдистә Пәйгамбәрдән (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) Гарәфә көнендә ураза тоту турында сорагач, аның: «Бу көндә ураза тотучының алдагы һәм киләсе елдагы гөнаһлары юылыр», – дип әйткәне китерелә.

Гайшә (радыйаллаһу ганһә) Мәсрук исмеле сәхабәгә: «Ий, Мәсрук, син Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) Гарәфә көне уразасын башка мең көн уразасы белән чагыштырганын ишетмәдеңме?» – дип әйткән (имамнар Бәйһакый, Тәбәрани җыентыкларында китерелә).

2 сөннәт гамәл: «әт-тәшрикъ» тәкбирен әйтү.

3 сөннәт гамәл: Гарәфәт көнендә госел коену шулай ук Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) сөннәте булып тора.

«Әт-Тәшрикъ» тәкбире

Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып (быел бу 20 августның иртәнге намазыннан башлап), Корбан бәйрәменең дүртенче тәшрикъ көнендәге (24 август) ахшам намазына тикле һәрбер фарыз намаздан соң тәшрикъ тәкбире укыла:

اللّٰهُ اَكْبَرُ اللّٰهُ اَكْبَرُ لَا إِلٰهَ إِلَّا اللّٰهُ

اللّٰهُ اَكْبَرُ اللّٰهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ

«Әллаһу әкбәр, Әллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләәллаah. Әллаһу әкбәр, Әллаһу әкбәр вә лилләәһил хәмд».

Тәрҗемәсе: «Аллаh Бөек, Аллаh Бөек, Аллаһтан башка илаh юк. Аллаh Бөек, Аллаh Бөек, бар мактаулар Аллаһка».

Әлеге тәкбирне әйтү бөтен җәмәгать өчен дә, аерым һәр кеше өчен дә вәҗиб булып санала. Ирләр тавыш белән әйтәләр, ә хатыннар эчтән генә кабатлыйлар. Вәҗиб булган витр намазыннан соң тәшрикъ тәкбире әйтелми.

Кемнеңдер бу көннәрдә кылынмый калган намаз бурычы булса, һәм ул калдырган намазларын тәшрикъ көннәрендә каза итеп укырга җыенса, аларны укыгач, тәшрикъ тәкбирен әйтергә тиеш. Каза намазларын бу көннәр узгач укыса, тәшрикъ тәкбире әйтелми.

■ **«Ислам дине нигезләре» китабыннан**

Сул кул белән ашарга ярыймы?

Дөреслектә, Ислам динебез – җиңел дин. Көндәлек тормышта башкарган эшләрдә дә без сөекле Пәйгамбәребезнең сөннәтләрен үтәп, савап ала алабыз. Әмма кайберәүләр белмәүләре яки билгеле бер сөннәтләрне кабул итмәүләре сәбәпле ялгыша. Көнбатыш этикетында ашаганда ризыкны ике кул белән дә алу, уң кулда – пычак, сулында чәнечке тоту каралган. Әлбәттә, мөселманнарга бу туры килми, чөнки Пәйгамбәребез сөннәте буенча без уң кул белән ашарга тиешбез. Бу гади генә сөннәтне дәлилли торган кайбер хәдисләрне китерәбез.

Гомәр бине Әбү Сәләмә исемле сәхабә мондый хәдис тапшырган: «Мин Расүлүллаһта (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) тәрбиядә булган бала идем. Ашаган вакытта минем кулларым бар тәлинкә буенча «йөри» иде. Пәйгамбәребез миңа: «Улым, ашый башлаганда Аллаһны зикер ит («Бисмилләһ»), уң кулың белән аша һәм савыттан (тәлинкәдән) үзеңә якынрак булган кисәкне ал», – дип әйтте. Моннан соң мин бары шулай гына ашадым» (Бохари, Мөслим җыентыкларында китерелә). Мөслим җыентыгында күпләргә билгеле мондый хәдис китерелә: «Берегез дә сул кул белән ашамасын һәм эчмәсен, чөнки сул кул белән шайтан ашый һәм эчә». Имам Әбү Давыд җыентыгына: «Һәрберегез уң кул белән ашасын, уң кул белән эчсен, уң кул белән алсын һәм уң кул белән бирсен», – дигән хәдис кергән.

Шул рәвешле, бу хәдисләрдән түбәндәге нәтиҗәне ясый алабыз: бар хәдисләрдә дә уң кул белән ашарга кирәклеге ассызыклана, бу ашау әдәпләреннән санала. Сул кул белән ашауның хөкеменә килгәндә, галимнәрнең фикерләре төрле. Мисал өчен, Ибне Гарәби «шайтанга хас бар гамәлләр дә хәрам булып тора» кагыйдәсеннән чыгып, сул кул белән ашауны тыя. Шулай ук сул кул белән ашау тыелмаган, әмма хупланмый торган гамәл (мәкруһ), дигән фикердә булган галимнәребез дә бар.

Имам Куртуби үзенең тәфсирендә болай ди: «Йәмин» (уң) сүзе «йумн» (бәхет) сүзеннән килеп чыккан. Аллаһы Тәгалә Җәннәт әһелләрен «әсхәбүл-йәмин» (уң якта булучылар) дип, уң якны зурлады».

Шул рәвешле, мөселманнар бу сөннәтне сәбәпсез кире кагырга, үтәмәскә яки инкяр итәргә тиеш түгел. Янә Имам Мөслим җыентыгыннан мондый хәдисне китерәсе килә: Пәйгамбәребез бер кешегә: «Уң кулың белән аша», – дип әйткән. Кеше: «Мин булдыра алмыйм», – дигән. Расүлүллаh: «Беркайчан да булдыра алмассың», – ди, чөнки бу кешегә, үзенең кирелеге һәм теләмәвеннән кала, уң кулы белән ашарга берни комаучауламый. Шул вакыттан алып, бу адәм беркайчан да уң кулын авызына китерә алмаган. Риваять буенча, аның кулы параличланган.

Бу хәдистәге кеше Пәйгамбәрнең киңәшен кире кага, сөннәтне үтәргә тырышып та карамый, шул сәбәпле, шундый хәлдә кала.

Әгәр кемдер җитди сәбәпләр аркасында (паралич, уң кулының бармаклары булмавы h.б.) уң кулы белән ашый алмыйча, сул кулы белән ашый икән, әлбәттә, моның өчен ул гөнаһлы булмас. Әмма сулагайлык бу сәбәпләр рәтенә керми, сулагай кеше уң кулы белән ашарга гадәтләнергә тиеш, ин шә Аллаh, аның бу кыска вакытлы уңайсызлыклары әҗер-савапсыз калмас.

■ **Хәсинә Гыйззәт**

Үзенчәлекле балалар өчен үзенчәлекле дәресләр

Авыру балаларга ярдәм күрсәтү «Зәкәт» Хәйрия фондының өстенлекле эш юнәлеше булып тора. Махсус программа кысаларында 2016 елда 39 баланың дәвалану курсларына акча күчерелә, 2017 елда аларның саны 57-кә җитә. Агымдагы елның 6 ае эчендә 34 балага матди ярдәм күрсәтелә. Сабыйларның күбесе төрле формадагы ДЦП белән интегә һәм мохтаҗ гаиләләрдә тәрбияләнә. Финанс ярдәмнән тыш, Фонд инвалид балаларны тәрбияләүче гаиләләргә азык-төлек белән булышлык күрсәтә. Мисал өчен, Корбан һәм Ураза бәйрәмнәре уңаеннан былтыр меңләгән кеше корбан ите белән тәэмин ителде, 400 гаилә азык-төлек пакетлары алды, 1300 кешегә бушлай кием-салым һәм аяк киеме тапшырылды, гошер сәдакасы җыеп таратылды. 2017 елның тагын бер башлангычы булып беренче инклюзив «Йөрәкле шәһәр» гаилә фестивале тора.

2017 елның ноябреннән «Зәкәт» хәйрия фонды мөмкинлекләре чикләнгән балаларга һәм аларның әниләренә ярдәм күрсәтү буенча уникаль проектны тормышка ашыра.

Әлеге Үзәкнең үзенчәлеге булып балалар укытучылар белән шөгыльләнгән вакытта әниләр өчен дә махсус дәресләр үткәрелүе тора. Бар дәресләр дә бушка үткәрелә. «Зәкәт» фонды әлеге проектын президент грантлары Фонды биргән Россия Федерациясе Президентының гражданлык җәмгыятен үстерүгә юнәлтелгән гранты ярдәмендә оештырды.

Бүгенге көндә проектта тулы, тулы булмаган һәм балаларның тәрбиягә алган гаиләләр катнаша. Аларның барысында да мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләнә. Балаларның яше 3 алып 27 кадәр. Бу үзенчәлекле сабыйларның диагнозлары да төрле: ДЦП, аутизм, сукырлык, саңгыраулык, генетик авырулар, төрледән-төрле физик һәм психик кимчелекләр; балаларны кайберләре үзләре йөри алса, кайберләре бөтенләй хәрәктләнә алмый диярлек.

«Яшьлек» яшүсмерләр клубы базасында (Годовиков урамы, 16 й.) урнашкан Үзәктә дәресләр атнасына өч көн: дүшәмбе, чәршәмбе һәм җомга үткәрелә. Хәзерге вакытта балалар өчен иҗади мастер-класслар, музыкотерапия, ИЗОстудия, әкияттерапия дәресләре, физик күнегүләр оештырыла. Әниләр өчен фитнес, бию, тегү дәресләре уздырыла. Кайбер дәресләр аерым үткәрелсә, психолог белән консультацияләрдә балалар белән әниләр бергә шөгыльләнә. Проектта каралган дәресләрдә үзенчәлекле балалар яңа шөгыльләр үзләштерә, аралашырга, төркемдә эшләргә өйрәнә, үзен җәмгыятьнең бер өлеше итеп хис итә. Бу мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә үз-үзен ачарга бик ярдәм итә. Музыкатерапия дәресләрендә балалар хис-тойгылары белән бүлешә, барабан, шакылдавык кебек инструментлар аша эмоцияләрен күрсәтә ала.

Барлык кызыксындырган сораулары белән һәрбер гаилә Фондка 225-33-22 номеры буенча мөрәҗәгать итә ала.

■ **Алсу Җәббарова,**
«Зәкәт» фонды хезмәткәре

Үзәк турында әниләр фикере:

«Бу – һәр хатын-кыз хыялланган дәресләр!»

«Минем кызымның төрле авырулары бар, аны һәрдаим карап торырга кирәк. Шул сәбәпле, мин озак вакыт үземә туры килгән графиклы яки бала караучы ялларга җитәрлек хезмәт хакы булган эш таба алмадым.

«Зәкәт» фонды оештырган проект миңа аның катнашучысы да, белгече булырга да мөмкинлек бирә. Кызым өчен минем күңелем тыныч – аны монда мин тәҗрибәлек укытучылар һәм волонтерлар кулында калдырам, монда ул үзе кебек үк балалар белән аралаша. Гомумән, без аның белән монда җәмгыятьтә яшәргә өйрәнәбез! Проект миңа бик ошый, мин үземне бер команда вәкиле итеп хис итәм. Мондый эш – минем өчен зур табыш, мин үз һөнәрем буенча эшлим, танышларым артты, иҗат өчен мөмкинчелекләр ачылды. Монда мин үземне кирәкле итеп хис итәм, бу минем кебек әниләр өчен бик мөһим. Эшем өчен мин хезмәт хакы алам, бу баламны дәвалау өчен өстәмә мөмкинлекләр».

■ **Татьяна Рябцева**

«Зәкәт» фондына зур рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Кызым Ләйсән үзәккә бик теләп йөри, монда без үз гаиләбезгә эләккән кебек булабыз: безне һәвакыт якты йөз белән каршы алалар, волонтерлар балаларыбыз белән уйный, төрле кул эшләре белән шөгыльләнә, әкиятләр тыңлый, җырлый h.б.

Ә әниләр белән шушы вакытта фитнес, тегү дәресләре, психолог белән консультация, диетолог, косметологлар белән очрашулар оештыралар. Киләчәктә дә бу үзәккә йөрербез, дип өметләнеп калам».

■ **Илсөя Хисамиева**

«Бу проект өчен «Зәкәт» фондына чиксез рәхмәтләремне җиткерәм. Безнең өчен бик кирәкле һәм кызыклы дәресләр оештырасыз. Безгә, үзенчәлекле балалар әниләренә, һәрвакыт аралашу җитми, бигрәк тә баланың авыруы җитди булып, ана кеше эшкә урнаша алмаса.

Фитнес, диетолог, шәрык биюләре – бу бит һәр хатын-кыз хыялланган дәресләр! Безнең өчен бу бушка оештырыла. Күпчелегебез мондый түләүле дәресләргә йөри алмый. Кул эшләре дәресләре бигрәк тә кызыклы, хәтта вакыт та җитеп бетми. Без букчалар, өй өчен кирәкле башка әйберләр тегәбез. Балалар һәм аналарга карата шундый игътибарлы булуыгыз өчен зур рәхмәт!»

■ **Светлана Александрова**

Кайсы мәктәпләрдә хәләл туклану каралган?

Һәр ата-ананы баласының хәләл ризык белән туклану мөмкинлеге борчый. Казан шәһәрендә хәләл ризыклы уку йортлары шактый. Аларның исемлеге азык-төлек һәм социаль туклану Департаменты сайтында китерелә. Сайтка тиз күчү өчен эзләү системасына «Поел и доволен» фразасын кертергә кирәк. Сайтта бүгенге көндә 2017 елда хәләл тукланулы булган балалар бакчалары һәм мәктәпләр исемлеге китерелә, алдагы уку елында да бу уку йортларында ризык хәләл булыр, дип көтелә. Шулай да, ата-аналарга балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә шалтыратып, моны ачыкларга киңәш ителә.

Район	Балалар бакчалары	Мәктәпләр
Вахитов р-ы	№188, 273, 273 филиал, 24, 89	№80, л-131, 18 Международная школа, г-1, г-27
Мәскәү р-ы	№105, 355, 126, 126 филиал, 184, 291, 372, 294, 2 гимн. каршындагы бал.бак-сы	г-12, г-2, г-17, г-94, 65, ТТЛ-2, ТТЛ филиал-2
Яңа Савин р-ы	№№110, 208, 28, 93, 302, 315, 99, 99 филиал, 405, 388	г-155, №113, 165, 146
Идел буе р-ы	№ 32, 358, 130, 163, 307, 71, Солнечный д/с,79 филиал, 396.	г-18, г-19, г-16, л-83, №68, 35, Международная школа (3,5), №42, 10
Совет р-ы	153, 154, 166, 211, 230, 38, 415, д/с при СОШ №108, 162, 167, 352, 100, 377, 377 филиал, 103, 112, 113, 124, 261, 272, 109, 330, 330 филиал, 394, 398, 399, 40, 402, 54, 60, 64, 67, 67 филиал, 8, 177, 6	№№171, 108, 149, 175, 180 11, г-20, Биектау р-ың №3, №4 мәктәпләре
Киров р-ы	№82	г-4, г-3, ТТЛ-4 г-15 ланч
Авиатөзелеш р-ы	№341, 34 филиал, 172, 348 филиал	№62, 60, 26, 10, г-5, г-14 ланч
Барлыгы	75	46

■ www.poelidovolen.ru

Мөселман балалар бакчалары

«Балалар» үзәге
Юнусова Гүзәл Талгәтовна,
Тел.: 89046656159,
yunusovagt@gmail.com

ИП «Азаматова»
Хайдарова Флюра Фәридовна,
Тел.: 89172225804,
fly4509@yandex.ru

«Сабыйлар» үзәге
Нурмөхәммәтова Ләйлә Ильясовна,
Тел.: 89173998166
suanasi@gmail.com

«Сабыйлар» үзәге
Габитова Илсөяр Минехаметовна,
Тел.: 89872884187
i-gabitova@mail.ru

«Хәзинә» (Яр Чаллы)
Әхмәтшина Ләйсән Раниловна,
Тел.: 89510660703
hazine-chelny@yandex.ru

«Бәхет ачкычы»
Ганиева Ләйсән, тел.: 89027113060

«Нурлы» балалар бакчасы
Фатыхова Мәрьям,
тел.: 89178563336

«Гөлбакча» (Яр Чаллы)
Габдуллина Сания,
тел.: 89033140983,
Зәйнуллина Миләүшә,
тел.: 89518954452

«Тәрбияле бала»
Хәйруллина Алсу, тел.: 89178826357

Без милләт аналары — милли хисле үзаңлы кешеләр тәрбияләргә тиеш
РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН

Ә сине милләтебез киләчәге борчыймы?

Мөселман кызлары өчен «Мозаффария» мәктәбе бинасын төзекләндерүгә үз өлешеңне керт!

Ярдәм итү ысуллары берничә
Уңайлысын үзең сайлап ал

Ярдәм итү ысуллары
SMS
3116
номерына kazan сүзе белән ярдәм күрсәтү суммасын язып SMS юлларга
МИСАЛ ӨЧЕН
kazan 500

«Зәкят» хәйрия фондына акча күчерү
БИК 042202837
К/С 3010 1810 2000 0000 0837
КОД ОКПО 50330799
ИНН 7702070139
КПП 526002001
ОГРН 1027739609391
Р/С 4070 3810 5252 4000 0135

halalstarter.com
сайты аша проектка акча күчерергә

«Сбербанк» картасына күчереп
5336 6900 3516 7669

Әйләнә-тирәне саклау – һәрберебезнең бурычы

Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән һәрбер әйбер хикмәт белән, барлык төр законнарга буйсындырылып яратылган. **«Аллаһ хозурында һәрнәрсә үлчәү беләндер».**

«Рәгыд / Күк Күкрәү», 13:8

«Тәхкыйк, Без һәр нәрсәне дөрес үлчәү белән үлчәп халык кылдык».

«Камәр / Ай», 54:49

Галәмдәге формаларның, элементларның, функцияләрнең күплеге кеше яшәешен бик күпкә җиңеләйтә. Аллаһы Тәгалә һәрбер әйбергә форма, аның функциясен, тәртибен биргән. Һәрбер мәхлук Аллаһы Тәгаләнең Бөеклеге, Кодрәтлелеге турында сөйли, Аллаһы Тәгаләне зурлый: **«Беләсеңме, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләгә җирдә вә күкләрдә булган мәхлукатлар тәсбих әйтерләр, кошлар да, канатларын һавада җәйгән хәлдә, тәсбих әйтерләр».**

«Нур», 24:41

Коръәнне ачып, бер-ике аятен генә булса да укып карасак, Җир йөзендәге һәрбер әйбернең бик күп мәгънәгә ия булганын, зур роль уйнаганлыгын аңлый алабыз. **«Ул – Аллаһ җирне сезгә түшәк кылды, җир өстендә сезгә юллар кылды, вә сезгә күктән яңгыр индерде. Аллаһ: «Яңгыр белән сезгә җирдән күп төрле үсемлекләр чыгардык. Без чыгарган ризыклардан яхшыларын ашагыз, вә хайваннарга яраклысын аларга ашатыгыз! Аллаһның бу эшләрендә гакыл ияләренә гыйбрәтләр бар», – дип әйтте».**

«Та һа», 20:53-54

Шулай ук Аллаһы Тәгалә бер генә әйберне дә максатсыз яратмаган. Дөньяда яшәү дәверендә, безне әйләндереп алган әйберләрне тиешле кебек кабул итәбез. Әмма безнең яратылуыбызның максаты булган кебек, аларның да үз максатлары бар: **«Без җирне һәм күкләрне вә алар арасында булган нәрсәләрне уйнап, шаярып, бушка гына халык кылмадык. Аллаһ дөньяны Үзенең бер генә Илаһ икәнлеген, һәммәсе Аллаһка мохтаҗ икәннәрен раслар өчен, вә кешеләрне ышану, ышанмауда сынар өчен төзелде, ләкин бик күпләр Безнең хак эшебезне белмиләр».**

«Духан / Төтен», 44:38-39

Шуңа күрә, Ислам дине күзлегеннән караганда, җиһанда булган барлык нәрсәнең дә максаты, мәгънәсе бар. Һәрбер мәхлукат бу дөньяны, үлем белән яшәүне контрольдә тотучы Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгаләгә гыйбадәт кылыр өчен яратылган.

Яшәү белән үлем дә Аллаһка гыйбадәт кылырга бер мөмкинлек буларак барлыкка китерелгән: **«Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белер өчен йөкләмәләр йөкләп, сезне сынамак булды, Ул һәрнәрсәдән өстен вә Ярлыкаучы».**

«Мүлек / Патшалык», 67:2

Кеше – галәмнең бер өлеше. Калган элементлар арасында урын алган зур системаның бер элементы гына булып тора. Шуңа күрә Коръәндә дә, хәдисләрдә дә кешенең шул элементлар белән мөгамәләсе турында бик күп тапкыр искә алына. Алар төрле була ала:

– галәмдә булган әйберләр турында уйлану, аларны күзәтү, өйрәнү;

– җир һәм су ресурсларын рациональ куллану;

– тирә-як турында кайгырту. «Һәрбер җан иясенә (хайваннар, бөҗәкләр, кошлар, кешеләр һ.б.) мәрхәмәтле булган кешегә күп әҗер-саваплар язылачак» (Имам Бохари).

Аллаһы Тәгалә кешене җиргә хәлифә итеп куйган, шуңа күрә кеше Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп яшәргә тырышырга тиеш. Хәлифә, ягъни Җир йөзендә бераз өстенлеге булуга карамастан, кеше бу дөньяның хуҗасы түгел. Күк, Җир һәм алар арасындагы бар нәрсә Аллаһы Тәгаләнеке. Кеше исә Аллаһы Тәгалә урнаштырган законнар буенча, бу дөнья мәхлукатлары турында кайгыртып яшәргә тиешлезат кына. Аллаһы Тәгалә кешегә Җир шарын әманәт итеп тапшырды, ә ышанып тапшырылган әйбергә карата мәрхәмәтле, игътибарлы булырга кирәк.

Бу дөньяда яшәгәндә, кешегә барлык мәхлукларның да хакларын кайтарып яшәргә кирәк. Шулай ук, үз дәверең турыда гына түгел, үзеңнән соң килә торган дәвер турында да уйларга кирәк. Табигатьтәге барлык ресурсларны кулланырга тырышу – файда алу дигәнне аңлатмый. Күргән барлык әйберне тотып бетерсәк, балаларыбызга, оныкларыбызга нәрсә калыр?

Һәркемнең дә табигать байлыкларыннан файдаланырга хакы бар һәм бу Аллаһы Тәгаләнең бүләге булып тора. Әмма без аларның сыйфаты начараюына, сан ягыннан азаюына сәбәпче булмаска тиеш. Кешелек иркен рәвештә гыйбадәт кылыр өчен яратылган нигъмәтләрне без үзебез юкка чыгарабыз, ә соңыннан шул нигъмәтләрне кире кайтарырга тырышып, гыйбадәт кылырга вакытыбыз да калмый. Адәм галәйһиссәләмне дә Аллаһы Тәгалә туфрактан бар кылганын исебездән чыгармасак иде: **«Ул сезне җирдән яратты вә җирдә торырга гомер бирде».**

«Һуд», 11:61

Табигатьнең үз схемасы бар дип карасак, ахыр чиктә, барлык чылбырларның азагы кешегә барып тоташканын күреп була. Кояш безгә җылылык бирә, хайваннар – ризык, чишмәләр – эчәр су һ.б. Әмма Аллаһы Тәгалә аларны да бер максат белән генә барлыкка китермәде: **«Җир вә күкләрне халык кылучы кодрәтле Аллаһ вә Ул, күктән яңгыр индереп, сезгә ризык булсын өчен төрле җимешләр үстерде, вә Ул диңгезләрдә Аллаһ әмере белән йөри торган корабларны, вә елгаларны сезгә ирекле кылды. Кояш вә айдан, көндез вә кичтән сезне файдаландырды. Вә Ул – Аллаһ сез сораганның барчасын бирде. Аллаһ биргән нигъмәтләрне хисаплап карасагыз, һич тә санап бетерә алмассыз, тәхкыйк, адәм баласы Аллаһка карышып үзенә-үзе золым итүче вә гаделсезлек кылучыдыр».**

«Ибраһим», 14:32-34

Бу аятьтән дә күп нәрсәнең кешегә буйсынганын белеп була. Әмма аларның барысын да Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән. Шуңа да, кешегә Аллаһы Тәгалә турында искә төшереп тору – аларның иң төп вазифалары. Бу исә аларны саклауны тагын да әһәмиятле итә. Кешеләр, җәнлекләр, бөҗәкләр, кошлар – табигать ресурсларын файдалануда барысы да бер хокукта. Ислам дине нәрсәгә дә булса зыян залуны, кимсетү, пычратуны тыя. Алтын урталыкны сайлап яшәргә тырышырга кирәк.

Су кыймәте

Аллаһы Тәгалә суны бик күп мәхлукатның асылы итеп кылган: **«Һәр терек мәхлукны судан халык кылдык».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:30

Бик күп мәхлукат: кеше, хайваннар, кош-кортлар, үсемлекләр, безнең бакчаларыбыз, иген-кырларыбыз – барысы да суга мохтаҗ итеп яратылганнар: **«Ул Аллаһ, Күктән яңгыр суын индерде, ул су белән һәртөрле үсемлекне җирдән чыгарып үстерде».**

«Әнгәм / Терлек», 6:99

«Язгы якта Җирне үләнсез, такыр хәлдә күрерсең, әгәр су индерсәк, терелеп, хәрәкәтләнер вә кабарып күтәрелер һәм ул яхшы үсемлекләрне үстерер».

«Хаҗ», 22:5

«Вә Ул – Аллаһ рәхмәте белән яңгыр алдыннан җил җибәреп кешеләрне шатландырадыр, ул җилләр кирәк җиргә болытларны алып килерләр, болытлардан пакь су индерелер. Ул су белән шәһәрләрнең үлгән табигатен тергезербез, янә Үзебез халык кылган хайваннарны вә күп кешеләрне эчертербез».

«Фуркан / Аеручы», 25:4-49

Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә үле җирне дә су индереп, кабат яшәртеп җибәрә. Бу Аллаһ барлыкка китергән суның никадәр мөһим роль уйнаганы турында сөйли. Әмма кешелек барыбер сулыкларны пычрата, чишмәләрне күмә. Ә чишмә «качса», аны кире чыгаруы бик кыен бит. Шуңа да Аллаһы Тәгалә бу мөһим яшәү чыганагын сакларга өнди: **«Белсәгез, эчә торган суларыгыз турында хәбәр бирегез! Болыттан ул суны сез индердегезме, әллә ул суны индерүче Безме? Әгәр Без теләсәк, ул суны эчәргә яраксыз итеп ачы кылыр идек. Ни өчен сез шөкер итмисез?»**

«Вакыйга / Хәл», 56:68-70

Су – кешенең чистарыну, сусавын басу, ашарга пешерү чыганагы. Су – меңләгән төр балыклар өчен яшәү урыны. Су – кораблар өчен «юл». Шуңа да Аллаһы Тәгалә су нигъмәтен бар кешегә дә җитәрлек итеп кылган. Суны калганнардан яшерергә, су аркасында кешеләр белән идарә итәргә ярамый. Шулай ук суны исраф кылу, ягъни кирәгеннән артык куллану да гөнаһ санала. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Елгада тәһарәт алганда да исраф кылып була», – дип әйтеп калдырган. Бу исә безгә бик игътибарлы булырга кирәк дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән нигъмәтләрен саклауда Үзе безгә көч һәм ярдәм бирсә иде.

■ **Ленар Хамматов**

Анар – җәннәт җимешләреннән

Аллаһы Тәгалә Коръәндә искә ала:

«Ул ике (җәннәт) бакчаларында төрле җимешләр, хөрмә вә анар агачлары бардыр».

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:68

«Без күп җимешле ботаклары җиргә якынлашкан хөрмә агачларын һәм дә йөзем, зәйтүн, анар бакчаларын үстерәбез, ул җимешләр төсе һәм тәме белән бер-берсенә охшаган, әмма кайберләре бер-берсенә охшамаган булыр. Аларны җимеш биргән һәм өлгергән вакытларында карагыз! Дөреслектә, ул җимешләрнең шулай өлгерүендә – ышанучы кешеләргә Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен белергә дәлилләр бар».

«Әнгәм / Терлек», 6:99

Әнәс (Аллаһ аннан разый булсын) риваяте буенча, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм болай дип әйткән булган:

«Сезнең бакчаларыгызда җәннәт анары орлыклары белән аталандырылмаган бернинди дә анар юк».

Гарәпләрдә анар (гранат) җимешен «румман» дип атыйлар. Җимешнең рус телендәге әйтелеше латин телендәге «granatus» – «бөртекле» дигән сүздән барлыкка килгән, ягъни күп кенә кызыл бөртекле (орлыклы) җимеш.

Элек-электән үк анар җимешенең файдалы үзенчәлекләре турында күп язылган. Өлгергән анар җимеше фруктозага, макро-, микроэлементларга, минералларга, витаминнарга бай.

Бер анар агачы гына да тормыш һәм көнкүреш өчен файдалы үзенчәлекләргә ия булып торган. Аның җимешләре сәламәтлек өчен файдалы һәм туклыклы булып саналган. Кабыгы белән тукымаларны төрле төсләргә буяганнар. Агачын эшкәртеп, көндәлек тормышта кирәкле вак-төяк эшләнмәләр ясаганнар. Кайрысыннан суалчаннардан дәваланырга мөмкин булган дарулар әзерләгәннәр, порошок ясап, тире авыруларын дәвалаганнар. Корыган яфракларыннан әчемлекләр әзерләгәннәр һәм кара буяу ясаганнар.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең күп кенә хәдисләрендә анар җимеше турында телгә алына: «Анар ашаган кешенең йөрәгендә Аллаһның нуры сүнмәс», «Анар сине 40 көн дәвамында шайтаннан һәм гөнаһлы фикерләрдән арындырыр».

Гали бине Әбү Талиб (Аллаһ аннан разый булсын) риваятендә китерелгәнчә, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Анарларны ашагыз, алар ашказанын ныгыталар», – дип әйткән. Бу сүзне хуплап, Әбүгалисина «анарның хәтта әче булганнары да ялкынсынулар, бизгәк авыруларына каршы, бәвел кудырткыч үзлекләргә ия», дип язган.

Анар согында 8 дән 20 % ка кадәр шикәр, 9 % ка кадәр лимон һәм алма кислоталары бар, кеше организмына кирәкле булган витаминнар, микроэлементлар бик күп. Анар согы салкын тию, ашказаны авырулары вакытында бик файдалы. Моннан тыш ул канның составын яхшырта, югары кан басымын төшерә. Шулай ук анар бөртекләрен төрле кайнар ризыклар әзерләгәндә һәм салатларны, кабымлыклар, десертларны бизәгәндә кулланалар.

Урта Азия илләрендә анар бөртекләре белән пылауны бизәү гадәтләнгән. Мөселманнарның аш өстәлендә һәрвакытта да анар табын күрке булып тора һәм аның белән, әлбәттә, кунакны сыйлау гадәте калган. Күпчелек мөселманнарда кайнатылган гранат согы киң кулланылышта. Аны итле һәм балык ризыкларына тәмләткеч буларак кулланалар. Көнбатыш илләрендә үзенчәлекле итеп әзерләнгән, «гренадин» дип аталган анар согы киң таралган. Ул шулай ук күп кенә балык һәм итле ризыкларга тәмләткеч буларак бара. Ширбәт дип аталган борынгы салкынча эчемлекне өйгә кергән һәркемгә тәкъдим иткәннәр. Ул йә ашау алдыннан, яисә ашаганнан соң бирелгән, ләкин беркайчан да ашаган вакытта түгел. Ширбәтне гранат согыннан яки цитрус җимешләреннән әзерләгәннәр. Аны гөлчәчәк (роза) суыннан әзерләнгән татлы сироп белән кушканнар һәм ул салкын килеш тәкъдим ителгән.

■ **Лилия Хәләфетдинова**

Коръәндә искә алынган үсемлекнең шифасы

Изге Коръәннең «Инсан» («Кеше») сүрәсенең 17 нче аятендә: **«Аларга (Җәннәт әһелләренә) тәмле сулар эчерелер, ул суның катыштырылган тәме зәнҗәбил кебектер»,** – дип әйтелә. Әлеге сүрәдә Җәннәттәге Сәлсәбил чишмәсенең суы зәнҗәбил кебек тәмле, файдалы вә хуш булуы әйтелә.

Зәнҗәбил үсемлеге безгә имбир буларак билгеле. Ул инде 3 гасыр элек тәмләткеч һәм шифалы үсемлек буларак таралган булган. Әүвәл имбир Һиндстанда үстерелә башлаган, ә бүгенге көндә ул Кытай, Индонезия, Австралия, Көнбатыш Африка һәм кайбер башка илләрдә дә үстерелә.

Борынгы чорда гарәп сәүдәгәрләре имбирне тәмләткеч буларак Европага алып килгән һәм монда ул бик тиз таралган.

Бар дөньяда билгеле мөселман галиме һәм табибы Ибне Сина беренчеләрдән булып имбирнең файдалы сыйфатларын һәм кеше организмына йогынтысын тасвирлаган. Табиб үсемлекнең борычка охшавын һәм җылыта торган сыйфаты турында язып калдырган. Шулай ук Ибне Сина имбир тамырының төнәтмәсен яки аны төеп, хәтерне яхшырту, күз авыруларын дәвалау өчен, ашказаны күбенүеннән кулланырга киңәш иткән.

Дөреслектә, X гасырда яшәгән галим ялгышмаган, моны бүгенге көн медицинасы дәлилләде. Коръәндә искә алынган зәнҗәбил тәмләткеч кенә түгел, ә антибактериаль, антисептик, какырта торган, кан тамырларын чистарта торган, организмнан холестеринны чыгара торган, авыртуларны баса торган, кан йөрешен, йөрәк эшчәнлеген яхшырта торган һәм башка бик күп сыйфатларга ия булган шифалы үсемлек тә.

Медицинада нигездә имбирнең тамыры кулланыла. Дару үләне булудан тыш, имбир яшьлек үсемлеге булып та санала, чөнки ул организмда җыелган токсиннарны чыгаруга сәбәп булып тора, иммунитетны ныгыта, нерв системасын тыныч-ландыра.

Имбир өстәлгән ризык тизрәк үзләштерелә. Россиядә аеруча имбирле чәй киң таралган. Кышларын мондый чәй җылыта, иммунитетны күтәрә һәм организмның гриппка каршы көрәшү көчен арттыра. Имбир чәенә гадәттә бал өстиләр.

Имбирне йөкле хатыннарга кулланырга киңәш ителми, бавыр, йөрәк авыруыннан интегүчеләргә саклык белән кулланырга кирәк.

Шул рәвешле, зәнҗәбил кебек гади генә үсемлектә дә Раббыбыз безгә күп нигъмәтләр биргән, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Үзенең колларына карата бик Мәрхәмәтле.

■ **Рәмзилә Шафикова**

Татарстан Диния Нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты Габдрахман Карабашиның «Китәбүт-тәҗвид» хезмәтен бастырды

Тәүге тапкыр әлеге китап XX йөз башында дөнья күреп, күп кенә төрки халыклар арасында таралган булган.

«Китәбүт-тәҗвид»тә кыскача тәҗвид (Изге Коръәнне уку кагыйдәләре) аңлатыла, авазларның мәхраҗлары, ягъни дөрес укылышы, әйтелү урыннары тасвирлана.

Китапка гарәп имләсендә Казан шәһәрендә 1906 елда бастырылган текст нөсхәсе һәм аның хәзерге әдәби татар теленә тәрҗемәсе кергән.

Китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт (РИИ бинасы) адресы буенча урнашкан кибеттән алырга мөмкин.

Телефон: +7 (843) 258-52-01

КАЗАН ӨЧЕН АВГУСТ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

Көн	Иртәнге намаз		Кояш чыга	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
	Сәхәр тәмам	Мәчет-ләрдә укыла					
01.08.2018	01:47	02:17	03:47	12:00	17:13	19:50	21:20
02.08.2018	01:49	02:19	03:49	12:00	17:12	19:48	21:18
03.08.2018	01:51	02:21	03:51	12:00	17:11	19:46	21:16
04.08.2018	01:53	02:23	03:53	12:00	17:10	19:44	21:14
05.08.2018	01:55	02:25	03:55	12:00	17:08	19:42	21:12
06.08.2018	01:57	02:27	03:57	12:00	17:07	19:40	21:10
07.08.2018	01:59	02:29	03:59	12:00	17:06	19:38	21:08
08.08.2018	02:01	02:31	04:01	12:00	17:04	19:35	22:05
09.08.2018	00:18	02:32	04:02	12:00	17:03	19:33	22:01
10.08.2018	00:31	02:34	04:04	12:00	17:01	19:31	21:56
11.08.2018	00:41	02:36	04:06	12:00	17:00	19:29	21:52
12.08.2018	00:49	02:38	04:08	12:00	16:58	19:27	21:47
13.08.2018	00:56	02:40	04:10	12:00	16:57	19:24	21:43
14.08.2018	01:03	02:42	04:12	12:00	16:55	19:22	21:39
15.08.2018	01:09	02:44	04:14	12:00	16:54	19:20	21:35
16.08.2018	01:15	02:46	04:16	12:00	16:52	19:17	21:31
17.08.2018	01:20	02:48	04:18	12:00	16:51	19:15	21:27
18.08.2018	01:25	02:50	04:20	12:00	16:49	19:13	21:23
19.08.2018	01:30	02:52	04:22	12:00	16:47	19:10	21:19
20.08.2018	01:35	02:54	04:24	12:00	16:46	19:08	21:15
21.08.2018	01:39	02:56	04:26	12:00	16:44	19:05	21:12
22.08.2018	01:44	02:58	04:28	12:00	16:42	19:03	21:08
23.08.2018	01:48	03:00	04:30	12:00	16:40	19:00	21:04
24.08.2018	01:52	03:02	04:32	12:00	16:39	18:58	21:01
25.08.2018	01:56	03:03	04:33	12:00	16:37	18:55	20:57
26.08.2018	02:00	03:05	04:35	12:00	16:35	18:53	20:53
27.08.2018	02:04	03:07	04:37	12:00	16:33	18:50	20:50
28.08.2018	02:07	03:09	04:39	12:00	16:31	18:48	20:46
29.08.2018	02:11	03:11	04:41	12:00	16:29	18:45	20:43
30.08.2018	02:14	03:13	04:43	12:00	16:27	18:43	20:39
31.08.2018	02:18	03:15	04:45	12:00	16:25	18:40	20:36

Беренче мөселман каналын хәзер Башкорстанда да карыйлар

«Хозур ТВ» тапшыруларын «Зеленая точка Уфа» телевидениесы һәм интернет-провайдеры челтәрендә карарга була, бу мөмкинлек Уфа, Нефтекама һәм Белорецк тамашачылары өчен ачылды.

Телеканал тәүлек әйләнәсендә татар һәм рус телләрендә эшли. Эфирда – кызыклы тапшырулар, ислам турында фильмнар, балалар өчен тапшырулар.

«Хозур ТВ»ны «Таттелеком» кабель челтәренең 36 нчы каналында, Huzurtv.ru сайтында һәм Youtube каналында карарга мөмкин.

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
Июль саны, №7 (276)

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
Электрон адресы: shura@huzur.ru
Телефон: +7 (843) 598-09-42

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
Камил СӘМИГУЛЛИН;
«Хозур» нәшрият йорты директоры
Ришат ХӘМИДУЛЛИН;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
Булат МӨБӘРӘКОВ;
Татарстанның баш казые
Җәлил ФАЗЛЫЕВ;
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
Габдулла ӘДҺӘМОВ

Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
Нәшир: «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2751
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Казан шәһәренең мәчетләрендә 24 нче июльдә таратыла.
График буенча бу санга 20 нче июль көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.